In my opinion, it is the mother who should appear in our minds, when we are asked about the person we admire and respect. It may be helpful if I quote Adriana Trigiani «No one worries about you like your mother, and when she is gone, the world seems unsafe, things that happen unwieldy. You can't turn to her anymore, and it changes your life forever. There is no one on earth who knew you from the day you were born; who knew why you cried or when you'd had enough food; who knew exactly what to say when you were hurting and who encouraged you to grow a good heart. When that layer goes, whatever is left of your childhood goes with her». I can not agree more. Only mother will always love and take care of us no matter how old we are.

So the person I admire is not famous at all.To the world, she has not done anything extraordinary like finding the cure for cancer or winning a Nobel prize but, to me, every little thing she does each and every day is amazing. Each morning I am awoken by her gentle and cheerful voice. She always tells me it is going to be a wonderful day, even in the stormiest of weather. She devoted all her time to our family and never puts her needs first. She has a very busy lifestyle getting up at half past five, making breakfast, taking my little brother to the kindergarten. And only then goes to work. No matter how tired she is when she returns home, she proceeds to cook a tasty meal.

But I admire my mother not only because she is such a warm and caring person. She is also a determined and strong-willed person, and sometimes even tough, but I know, this comes from the desire to do things well. I've always seen my hero and my defender in her. She has always been my «stone wall». She has guided me in the right direction from the day I was born and I am constantly thankful for that. My mother is a person one cannot fail to admire. Is it any wonder that I have dreamt of growing up to be just like her?

**Баталова Полина, 10класс**
**Руководитель – Мурзалиева Т.А., учитель английского языка МБОУ «СОШ №33», Нижнекамск**

Good morning. I am delighted to be here today to tell you about the person I admire.Have you ever stopped to think who has impacted your life the most? Most people would say their parents and next to them, their friends.

But what is a good friend? People say, a good friend is someone you want to do life with, until the day you die. When I think about it, I can't imagine living my life without Darya the person I can't stop admiring. Without her my life would be so empty, it would seem so meaningless. She is the friend that makes my life so rich.

I've met Dasha at school, in the second year. At first I thought she was nasty and too selfish, because at that time she didn't speak to anyone, but one day we started to talk to each other during our art classes and I suddenly realised that she was really nice and cute. And I still think she is. You may ask me why. Well, I'll tell you.

First of all, Darya has a brilliant mind, she is the smartest and most intelligent person I have ever met. And I want to be as clever and as purposeful as she is. She never gives up on life and always trying to her best. When I think of her, I know that anything is possible as long as you really want it and work hard to achieve it. It is she that makes me learn more and more about world around me.  And I think it proves that has a great influence on me.  She has always been my source of inspiration and pillar of strength.

Also she has fantastic talent to make friends, because she is a very outgoing person and  slow to take offence. Dasha  has a great sense of humor and can make everyone burst out laughing. I bet, everyone who knows her has heard her hilarious stories and funny jokes. And I really admire her being such an easy-going person.  Moreover she is a person of taste. She can recommend me good music to listen to, intesting books to read and tasty meals to cook. As for Christmas presents hers are always the best.

What's important to mention Darya is a perfect friend. I like that she is a reliable person and good at keeping secrets. She  has been very patient with me and supports me in everything I do. She has done a lot to boost my self-confidence and self-esteem. We are always trying to help each other and when we are together, we enjoy ourselves very much.  Of course we sometimes can argue or quarrel, but not for too long. I appreciate our friendship and the fact that she has never left my side makes me happy. I can not imagine my life without Darya. She is a fantastic person and I'm really proud of being her friend.

Now I hope I' ve succeeded in  making you believe that   Darya is a person who deserves my admiration.I thank you for giving me this occasion to explain how I admire my best friend.

## Категория «Учителя»
## «The person that influenced my career choice»

**Ханнанова Гузель Закиевна, МБОУ «Сармановская СОШ», с. Сарманово Сармановского района, учитель английского языка**

Hello, everyone. I'm Khannanova Guzel Zakievna, an English teacher. I had never thought of being a teacher, when I was a schoolgirl. My favourite subject was Russian language, I adored my teacher of Russian. Once we were discussing my future profession and I told her that I'd like to be a teacher of Russian. She became a little bit nervous when she heard it. She said something like "Are you crazy?" Now I have understood why she was shocked by my decision. But at that time I decided to be a teacher, an English teacher not Russian one.

I've been a teacher for 9 years now, and going back to my childhood I realize that the main person that influenced my career choice was my granny. I was inspired by her unconsciously. I'll try to explain how it happened. You know my granny was not a teacher, she was a milkmaid in the village the most part of her life. She loved her job very much, she told about her cows as if she told about her children. All of her cows had names and she liked to repeat that even animals can understand kindness. I guess this fact inspired me to choose the profession of a teacher. Dear colleagues, I think you will agree that our profession is pointless without love and kindness.

Another quality of my granny's character which influenced me was her sense of humour. She told a lot of funny but at the same time instructive stories from her experience. I was admired by her ability to explain difficult things easily. We know that students enjoy being entertained and amused. Sometimes I tell my granny's jokes to my students.

Summarizing I'd like to tell that the character and personality of my granny was crucial in choosing my career. Today she is 92 years old and she is still full of energy, cheerful and really an inspiring human being.

**Хатбуллин Рашид, учитель англйского языка МБОУ «Лицей-интенат №24» НМР РТ, г. Нижнекамск**

I believe every person has got a hero. Someone who encourages us to become better versions of ourselves, to choose a path and follow our hearts along that bumpy road and dodge the obstacles hoping to achieve the highest levels of success and maybe even understand the very meaning of our existence. It can be a movie or a book character, a loving parent or a relative, a superstar or just a neighbor. So, let me tell you about my hero.

It all started for me in the childhood. I was destined from above to be the eldest child in the family and having three siblings gives one quite an experience in dealing with kids. I learned it early in life - taking responsibility for the ones you care about, those who look right into your eyes and expect some example, experience, adventure. For those who are ready to follow you no matter what, who rely on you to lead them and not to fail, not go astray...

Well, whatever, it wasn't quite a dream of my life to dedicate myself to the holy mission of bringing up the perfect future generation. I got no teachers in the family or among relatives or neighbors, nobody to set a good example of an educator. So, no background to support my choice of the current career.

In 1998 I went to Tatar Turkish High School (it carried that name at that time) and that was a start I guess. That was a new world for most of the students there and I was no exception, because the way teachers treated us was extraordinary, not the way we got used to be treated in our previous schools. We were like friends or even brothers to each other, like elder brothers teaching us about the world and life. It was grade 10 when we got ourselves a new classroom teacher, Mustafa Alyar, who seemed very strict at first glance but then turned out to become my closest friend and mentor. He used to spend a lot of time with us. We would play some games, do some sports together. I still

remember the picnics, tea parties and talks we had. He would tell us inspirational and motivational stories and then we would discuss them for hours draining the teapot and eating all the biscuits and other sweets he treated us with. Those are the moments I miss most. He rarely got angry with us and if he did, and it was really hard to keep temper with us, he would make up for it. No matter how badly we failed, he wouldn't be disappointed and look at the bright side of everything, like every failure had its own benefits.

Grade 11. We were all about to say goodbye to our school life and follow our dreams in the adult life. Everybody was anxious to plunge into the real life full of ups and downs, risks and challenges, hopes and losses. I was dreaming of becoming a computer programmer. No, seriously, it was the dawn of computer technology and just like boys back in time when Yuri Gagarin made his first flight into the open space were crazy about becoming cosmonauts, I was eager to chase the career of a computer geek as computer was the only wonder I had seen in my life. Thankfully, I gave up that idea when there still was time and decided to try linguistics since by that time I could freely speak 4 languages and learning 1or 2 more languages would make me a superstar.

One day Mustafa bey beckoned me for he wanted to have a talk with me. We sat on a coach in the dorm's sitting room and started talking about things. And then he asked me what I wanted to be, so I told him about my plans. He was pleased to hear about my change of plans and all. But his next question caught me off guard. He asked me if becoming a teacher was of any option. Since for that time teacher's job was considered the least favorable job especially with the young men, I was really shocked that my teacher asked me that sort of a question. I didn't want to break my mentor's faith in me, so I just told that I considered it as a last possible option if nothing else worked out. He didn't seem to be disappointed as he never lost faith in his students. "I'd be very happy if you kept that option among all others." he said. I didn't pay much attention to those words then, just nodded in agreement.

On 20$^{th}$ of June we had our graduation party. I had to leave it for the courses I was to attend the next day. And that was the last day I actually saw my teacher Mustafa bey, because a few days later he had to leave the country, well, he and some other teachers were forced to leave for some blithe political issues between the governments of our countries and I have never seen him since…

That was a shock for me no doubt, but I had to study hard to become a university student, which I managed to do in the end. Although I was a student of pedagogical university, at first I still wasn't eager to become a teacher. And one day it all dawned on me. It was an ordinary day, nothing special happened or was planned, it just came to me. I was at the university's front door, wearing my casual clothes, when some inner voice or my second self told me "I am gonna be a teacher!" Maybe it was some sort of the reaction to the turn of recent events, my graduation from school, coming to another city to get higher education, having lost contact with my mentor – I don't know. But since that day forth I never had any second thoughts about my future career and I never wore nothing but a suit, a shirt and a tie as I had never seen my mentor dressing up in anything casual…

I have no doubt that my beloved teacher, friend and mentor is the only person why I am what I am. I got a little brother who has become a teacher this year too, and as he has always been looking up at me I truly believe that Mustafa abi has affected more than one life.

I wish I met him and told all of those looking right into his eyes, and hug him as he always used to do when greeting us. I really hope this day will come and my mentor will be pleased to acknowledge his apprentice following up in his steps…

Thank you all very much for your attention!

## II Республикакүләм ораторлык осталыгы конкурсы «Speaking Contest»

***«Сүзне төрлечә әйтеп була. Бер үк сүзгә теләсәң-шатлык, теләсәң-кайгы, кирәк чакта-ихтирам яисә нәфрәт сыйдырып була. Сүз-шул ук, ә аның тәэсире тулысынча үзгә. Искиткеч нәрсә ул – сүз».***

*Миргазыян Юныс*

**Чыгышларның темалары:**

**4-6 сыйныфлар - “Минем яраткан әкият героем”**

**7-8 сыйныфлар - “Минем яраткан әдәби героем”**

**9-11 сыйныфлар - “Мин бу шәхескә сокланам”**

**Укытучылар - “Минем остазым”**

**Түбән Кама, 2019**

## «4-6нчы сыйныф укучылары» категориясе

**ТР Баулы муниципаль районы 6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**Юнысова Эльвина Наилевна, 5А классы**
**Җитәкчесе – Хафизова Гөлнур Вильдановна, туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Китап – белем чишмәсе. Сез бу мәкаль белән килешәсезме? Мин килешәм. Ни өчен дисезме? Чөнки дөньяда китаптан башка яши алмыйм мин. Китапларда бит бик күп акыл хәзинәсе тупланган. Без китаплар аша дөньяны танырга өйрәнәбез. Китап геройларыннан үрнәк алабыз яки кайберсенә охшамаска тырышабыз.

Сезтелевизор карарга яисә кызыклы китаплар укырга яратасызмы? Ә мин кызыклы, мавыктыргыч китаплар укырга яратам. Кечкенәдән үккитаплар укып үстем. Әле укый белмәгәндә, әнием миңа бик матур әкиятләр укый иде. Мин әкиятләрне тыныч кына, сабыр гына зур кызыксыну белән тыңлый идем.

Хәзер мин бишенче сыйныфта укыйм инде. Ләкин әкиятләр укуымны әле дә дәвам итәм. Күптән түгел “Үги кыз “дип аталган татар халык әкиятен укып чыктым. Гаделлек, яхшылыкның явызлыкны җиңүе, әкияттәге фантазия – болар барысы да минем күңелемә кереп калды. Әкиятнең төп герое – үги кыз. Әкиятне уку барышында мин үги кызны бик кызгандым. Аның үз әнисе юк, ул үги әни белән яши. Шуңа карамастан, кешелеклелек сыйфатларын бер дә югалтмаган ул. Үги булса да, Убырлы карчыкка эләккәч, аңа яхшы булсын дип, аның әйткәннәренең киресен эшли, ул хезмәт сөючән, булдыклы һәм һөнәр сөюче кыз. Төп герой тәмле телле, олыларга карата хөрмәт күрсәтә һәм карт кешене рәнҗетүдән курка. Убырлы карчык кызның бөтен яхшылыклары өчен аңаалтын-көмеш белән тулган яшел сандык бүләк итә. Үги кыз барлык сынауларны да җиңә һәм язмыш тарафыннан бүләкләнә. Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне дигән мәкаль үги кызга бик тә туры килә. Ә сез килешәсезме?

**Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**Галимов Әмир, 4Б класс**
**Җитәкчесе–НуруллинаА.А., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Мин әкиятләр укырга бик яратам.Минем иң яраткан әкият героемГабдулла Тукайның “Шүрәле” әкиятендәге Былтыр образы. Былтыр мина үзенең тапкырлыгы, кыюлыгы белән бик ошый.Ул - бернәрсәдән дә курыкмый торган, бернинди кара көчләргә бирешми торган, гади авыл егете. Урманда Шүрәлене күргәч тә, ул куркып калмый.

— Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.
Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!

Шуннан соң әкияттә Шүрәленең бармаклары кысылып калу мизгеле сурәтләнә. Әлеге сюжетта Былтырның куркусызлыгы һәм зирәклеге ачыла.

Тукай бу образ аша гади авыл егетенең генә түгел,ә татар халкының көчле,батыр, кыю халыкикәнен күрсәтергә тели. Миншул бөек халыкның батыр бер улы булып үсәргә телим. Мин үземнең татар булуым белән горурланам!

**Седышев Данил, Түбән Кама шәһәре**
**32 нче гимназиянең 4 нче б сыйныфы**
**укучысы**
**Җитәкчесе- Мубаракшина Р.Р.**

**Ш**ук та үзе, шаян да
**Ү**чекли, ди, һәркемне.
**Р**әсем, мультфильм,
**Ә**киятләрдә яши.
**Л**әкин аны Былтыр гына
**Е**л саен алдап йөри.

Күрдегезме, белдегезме
Яраткан героемны?
Алай дисәм,
Юктыр бер генә адәм
Шүрәлене белмәгән.
Үзе усал, үзе ямьсез,
Куркыныч та җитмәсә.
Яратырга була соң
Аның кай җирен генә?

Ышанмыйсыздыр әле,
Сез бит белмисез әле
Яңа елның кичендә
Шүрәле килде безгә.
Арча ягыннан түгел
Безнең урманнан килгән
Миннән башка бәйрәмне
Үткәрмәсеннәр дигән.

Кот очарлык ямьсез үзе,
Кәкре аяк-куллары.
Куркытып йөри шулай
Кечкенә балаларны.
Ул безгә килгән иде
Бәйрәмне бозам, диеп.
Кети-кети уйныйм да,
Чыршыларын урлыйм да
Зур тозак корам диеп.

Тик хәйләкәр, өлгер булдык
Без дә Былтыр шикелле.
Матур гына бәйрәм иттек
Дус итеп Шүрәлене.
Бу әкият кунагына
Шаккатты бөтен шәһәр.
Килегез дә күрегез
Минем сүзләремә сез
Ышанмасагыз әгәр.

**Шалдымова Юлия, Түбән Кама шәһәре**
**32 нче гимназиянең 4 нче г сыйныфы укучысы**
**Җитәкчесе- Мубаракшина Р.Р.**

*Су анасы*
Көнгә каршы ялтырыйдыр
Алтын тарак кулында.
Сөйлим әле бүген сезгә
Су анасы турында.

Тузган чәчле, җен төсле,
Ул куркыныч булса да,
Яхшы тәрбия бирә
Буыннан буыннарга.

Карак малайларны ул
Алдамаска өйрәтә.
Табигатьне сакларга
Кирәклеген искәртә.

Су кергәндә
Сак булыгыз
Тирәнгә кермәгез, ди,
Әниегезне борчуга
Сез салып йөрмәгез, ди.

Истә тотып үсәбез
Без аның киңәшләрен.
Иң кайгыртучан герой
Ул шигъри тәлгәшләрнең.

**Бәширова Адилә**
**Түбән Кама шәһәре 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5В сыйныфы укучысы**
**Җитәкчесе-ХикмәтуллинаЛ.З., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Дөньяда китаптан башка яшәү мөмкин түгел. Китапның шытырдап торган битләрен ачасың да аның дөньсына чумасың......ах, аның исе.....!

Кечкенә вакытта, әле укый белмәгәндә, миңа экиятләрне, әнием бишек җыры беләнбергә җырлап сөйли иде:
Әәә-әәәә, мммм-ммммм,
Адилә йокыга китә....
Адилә йокыга китмәсә,
Аны аю апкитәә...
Ирексездән әкият дөньсына чумасың...

Халкыбызның авыз иҗатында әкиятләр иң мөһим жанрларның берсе.Алар гасырлар буе телдән-телгә күчеп килгәннәр, аларны тыңлау рәхәт, мавыктыргыч итеп сөйли белү-үзе бер талант! Әкиятләрнең теле гади, аңлаешлы, образлы әйтелмәләргә бай була. Шуңа күрә аларны балалар да, өлкәннәр дә яратып укыйлар һәм тыңлыйлар.

Минем иң яраткан әкиятем –“Үги кыз“. Татар халык әкиятләрендә үги кыз образы еш очрый. Бу кыз бала әнисе тарафыннан җәберләнгән, авырлыклар күреп үскән. Аны урманга алып

барып адаштыралар, чөнки ул-артык кашык. Үзе яхшы булгач, юлында да гел яхшы кешеләр очрый аның. Убырлы өенә эләгә, карчык кызны төрле яктан сыный, намусы чиста булуына инана. Кыз тәмле телле, олыларга карата бик мәрхәмәтле, хөрмәт күрсәтүчән, карт кешене рәнҗетүдән курка. Аның карчык биргән алтын-көмешләргә дә исе китми.
Сүземә йомгак ясап, шуны әйтәсем килә:“Үги кыз” әкиятебезне өлкәннәрне рәнҗетмәскә, кеше әйберенә рөхсәтсез тимәскә, кешеләрнехөрмәт итәргә, түзем сабыр булырга өнди.
Сабыр төбе сары алтын,
Түзим әле, дөнья узе-
Бер түләр алтын хакын!

**«Төлке белән Каз»**

**Белова Валерия Павловна,**
**Казан шәһәре Мәскәү районы 9нчы гимназиянең 4В сыйныфы укучысы.**
**Җитәкчесе – Абитова Я.С., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Минем иң яраткан әкиятем - “Төлке белән Каз”. Ә анда иң яраткан героем - Каз. Әлеге әкияттә каз гармунда уйнап утыра. Ә төлке аны эләктереп ала һәм ашыйм, ди. Каз үзенең биергә яратканын һәм соңгы тапкыр биергә теләвен әйтә.Төлке риза була. Ә каз алдалый, ул очып китә.
Миңа бу әкияттә Каз бик ошады. Башка әкиятләрдә Төлкеһәрвакыт хәйләкәр, ә бу әкияттә киресенчә, Каз бик акыллы, хәйләкәр, җитез. Бик оста биюче. Аның биюе миңа бик ошады. Каз Төлкене алдалады. Мин Каз өчен бик шатландым. Казга шаккаттым.

**Мусина Айзиля**
**Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**Җитәкчесе- Исмәгилова И.Г.туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Яраткан әкият героем- “Мең дә бер кичә” әкиятеннән Шәхрезадә .

Ул бер кисәк бур һәм чүпрәк алып ишегалдына чыкты. Ләкин лампаны чүпрәк белән ышкый башлауга, җир тетрәп китте һәм аның каршына бик зур гәүдәле бер җен килеп басты. Галәветдиннең анасы, кычкырып, һушсыз булып җиргә егылды. Галәветдин анасының кычкырганын ишетте. Шул ук вакытта Галәветдингә сизелерлек булып,бүлмә караңгыланып китте. Галәветдин ишегалдына йөгереп чыккан вакытта, анасы инде җирдә егылып ята иде, аның янында лампа, ә ишегалды уртасында җен басып тора иде. Җен шундый зур, аның башы җирдән караганда бөтенләй күренми иде. Ул кояшны каплап торганлыктан, эңгер-меңгер вакытындагыдай караңгыланып киткән иде. Галәветдин лампаны кулына алды. Шулчакта күк күкрәгәндәй көчле тавыш ишетелде…

Ә менә аннан сон нәрсә булганын, мин сезгә иртәгә сөйләрмен.

...

Я, сез мине таныдыгызмы?...Әссәләмәгаләйкүм барыгызга да!

Сезнең каршыгызда “Мең дә бер кичә” әкиятеннән Шәхрезадә.

Мин кечкенәдән үк әкиятләр яратам. Шулай бервакыт әнием миңа бик тә кызыклы әкиятләрукыйбашлады. Андагы әкиятләрне мин бертуктамый тыңларга әзер идем. Ул китап “Мең дә бер кичә” исемле иде. Шул көннән башлап,минем күңелемтүрендәШәхрезадә

образы уелып калды. Ни өчен дисезме? Бик тә акыллы булганы өчен! Зирәк ШәхрезадәШәхрияр патшага мең дә бер төн буена кызыклы һәм мәгънәле әкиятләр сөйли. Һәм шуның белән үзен дә һәм үзе кебек бик күп кызларның гомерләрен саклап кала.

Акыллы булу үземә дә бик ошый. Шуңа күрә мәктәптә бик тырышып укыйм. Әле миңа “Син бик матур”дигән дә булалар.Анысын белмим, минемчә ,кызларматурлыгы белән генә түгел, ә акыллары белән күркәм булырга тиеш! Нәкъ Шәхрезадә кебек!

**Гатина Нурия, Чирмешән районы “Чирмешән лицее” ның 4 сыйныф укучысы**
**Җитәкчесе-Гирфанова Г.С., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Миңа Фәнис Яруллинның " Хәтерсез күке" әкияте ошый.

Әкият-ул халыкның уй-хыял җимеше. Кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

ФәнисЯруллинүз әкиятендә күкене нинди кош итеп сурәтләгәнен беләсезкиләме? Бу әкияте аша Фәнис абыйбезгә нәрсәәйтергәтеләдеикән?

( Күке кычкыргантавыш астында укучысөйли )

- Сез миннән сорыйсыз "Эй, күке, нигә болаймоңаясың? "дип.

Ничек индемин моңаймыйм?! Эчем тулы сагышбитминем. Сез- кешеләр безне аңламыйсыз.Безне башкакош оясына күкәйсалган өчен гаеплисез. Балаларын үстерергәяратмыйдисез. Keминде үзбаласын яратмасын.

Хәтеребезбик начар безнең. Үз оябызны таба алмыйбыз. аннары аптырыйбызда башка кош оясынайомырка салабыз,икенче йомырка салырвакыт җиткәч,тегекошның да оясын югалтабыз. Әле анда барабыз,әле монда барабыз.Бөтен урманбуйлап оябызны эзлибез. Арып бетәбез.

Их аңламыйлар безне, аңламыйлар! Безнеңкүңелебездә бернинди начарлык юк бит.Хәтеребез генә начар безнең. Без "Күк-кү! Күк-кү!" дип үзебезнеңбалаларыбызны чакырабыз. Бәлки,тавышыбызны ишетепкилерләр,дибез. Безнең дә үз балаларыбыз турында кайгыртасыбыз, аларныңүскәннәренкүрәсебез , шатланасыбыз килә."Күк-кү! Күк-кү!"

Әкият - ул хыялны укучыга җиткерү жанры. Фәнис абый эти-әниләр үз балаларын үзләре карап үстерсә иде дип хыяллана.

## “7-8нче сыйныф укучылары” категориясе

**«Шәвәли – минем яраткан әдәби героем»**
**Мөхәмәтҗанов Ильмир, Түбән Кама шәһәре**
**3нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**7В сыйныфы укучысы**
**Җитәкчесе – Гиниятуллина А.Р..,**
**туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Исәнмесез! Хәерле көн! Бүгенге бәйгедә мин “Минем яраткан әдәби героем” темасы буенча катнашырга булдым. Мин туган телемнебик яратам. Татар телендә язылган китапларны кызыксынып укыйм. Миңа аеруча Шәүкәт Галиев һәм аның әсәрләре ошый. Алар “Тәрбия мәктәбе” кебек тоела.Китаплары- мәктәп, ә аларда тупланган әсәрләр- дәресләр. Шәүкәт Галиевның дәресләре тормышта кирәк булганбелемне бирә. Аның “дәресләрендә” теге яки бу нәрсә ярый, ярамый дип төгәл бер кагыйдә белән әйтелми, ә безгә кызыксыну уятырлык итеп, шаян тел белән аңлатып бирелә. Менә шулай итеп ул безне бер көлдерә, бер уйландыра.

“Үзең яхшы булсаң, кеше дә сиңа яхшы гамәлләр кылыр, үзең начар булсаң -кеше дә сиңа һәрвакыт начарлыклар эшләр”,- диеләтатар халык мәкалендә. Шулай булгач, башкаларның сиңа уңай караштабулуын теләсәң, үзең яхшы күңеллекеше булырга тиешсең. Ә моның өчен нинди булу кирәк?Иң мөһиме- тәртипле булу. Минем яраткан язучым нәкъ шушы темалар турында яза да инде.

Шәүкәт Галиевкитапларындагы Шәвәли – минем яраткан әдәби героем. Шәвәли образы - тәрбия мәктәбендәге бер шаян малай.Ул бөтен кешенең игътибарын җәлеп итеп тора.

Шәвәли образы безгә бик якын герой һәм аның мисалында Шәүкәт Галиев безгә яхшыны начардан аера белергә, тәртипле булырга, әдәпле булу кагыйдәләренә өйрәтә.“Тәрбияле булу” - һәрвакыт бик актуаль сорау. Шәүкәт Галиев моңа җавап эзләгән. Бу турыда бик күп шигырьләр язган.“Автобуста” шигырендә дә шуны күрәбез:

-Менә урын-
Утыр, бабам.
Ә мин җәяү
Басып барам!

Аның теләге безне, үзенең шигырьләре,Шәвәли образы аша, кечкенәдән үк тәрбияле итеп үстерү булган.

“Гафу үтендем” шигыре аша безне гафу үтенә белергә өйрәтә:

Ялгыш аягына баскач,
Гафу үтендем.
Борынымны ялап,
Кәефе килде этемнең!

Ялгышлык эшләсәң, бу иптәшең алдында гафу үтенергә кирәк. Бу тәрбияле булу билгесе.

“Мин” шигырен укыгач, без, көлештек. Шәвәли үзе тыйнак, ә үзе ничек мактана. Шигырь безне әдәпле булырга өйрәтә. Мин-минлек – начар гадәт. Автор төп герой - Шәвәли исеменнән сөйли.

Гомумән,әдәби геройлар кебек бик күп. Ләкин Шәүкәт Галиев шигырьләрендәге Шәвәли образы үзенең “сәерлелеге” һәм шаян характерда булуы белән аерылып тора.Минем тәкъдимем: татар теле, уку дәреслекләрендә, сыйныфтан тыш уку чараларындааның шигырьләрен күбрәк укырга кирәк. Ә менә “Шәвәли”не безнең дәресләргәкунакка чакырсалар, безгә тагында күңеллерәк булыр иде. Әлеге образ аша әдәпле, тәртипле булу кагыйдәләрен өйрәнү кызыклырак булыр иде.

**Фәрхуллина Азалия Илһамовна**

**Байкиев К.С. исемендәге Ишкурма кадет интернат-мәктәбе**
**Җитәкчесе- Гарафиева М.И. туган тел һәм әдәбият укытучысы**

*Гадилә – минем яраткан әдәби героем*

Тирән дулкынлану беләнФ.Яруллинның "Ак төнбоек"повестен укып чыктым. Повесть миңа яшүсмерләрнең психологиясен аңларга, бәя бирергә, язучының әдәби осталыгын тагын да ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итте.

Ф.Яруллин − безнең әдәбиятта инде күптән хөрмәтле урын яулаган, укучылар мәхәббәтен казанган әдипләрнең берсе. Язучы үзенең әсәрләрендә халкыбыз тормышының байтак якларын чагылдырды, гүзәл образлар тудырды.

Мин Ф. Яруллинның "Ак төнбоек" повестеның эчтәлегенә тукталып китмәкче булам.

Әсәрнең сюжеты катлаулы түгел. Кечкенә чакта Гадилә белән Шөһрәт бергәләп су коенырга бик яратканнар. Бервакыт, шулай су коенганда, Гадилә эчкәрәк кереп китә. Аны көзән җыера һәм ул бата башлый. Моны куреп Шөхрәт дустын коткарырга ашыга. Ул аны коткара, бөтен кеше аны мактый. Башта бу хәл Шөхрәтне уңайсызлыкка куя, вакыт утә торгач, ул инде Гадилә аңа бурычлы дип саный башлый. Шөхрәтнең мыскыллавына тузә алмыйча, Гадилә аның яңагына суга. Шуннан соң,ике дусның юллары аерыла.

Автор геройларын төрле яктан ачып бирергә тырышкан, аларның характерлы үзенчәлекләрен күрсәтә алган.Әмма минем Шөхрәткә дә, Гадиләгә дә тукталып үтәсем килә. Аларны чагыштырып, бәя бирәсем килә.

Бу тормышта кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен. «Ак төнбоек» хикәясендә Ф. Яруллин җитди мәсьәлә күтәрә. Шөһрәтнең артык масаеп китүе аркасында килеп чыккан каршылыкны сурәтли. Кешегә яхшылык эшләү − әйбәт гадәт. Әмма шуның белән гел мактанып, кешенең исенә төшереп, яхшылыгың өчен «хак» сорап тору − гайрәтне чигерә торган ямьсез сыйфат. Ул тумыштан килми, кешене артык мактап җибәрсәләр, кайберәүләрдә масаю, кәпрәю барлыкка килә. Ул, йогышлы чир кебек, кешенең холкын үзгәртә дә куя. Шөһрәттән иптәшләре дә читләшә, хәтта бергә уйнап үскән дустын югалта. Монысы инде − Шөһрәт өчен зур җәза. Ә бит Гадиләне ничек кайгырта белә иде, дуслыклары саф, төнбоеклы күлдәй матур иде.

Шөһрәтне дан сөю, масаю харап итә. Малай чактагы гүзәл сыйфатлары үзгәрә: күңеле тарая, җаны ваклана. Шулай да, Шөһрәт булган хәлләрдән сабак алыр, аңа элеккеге олы җанлылыгы, киң күңеллелеге кире кайтыр, дип ышанасы килә. Димәк, тормышта масаеп йөрергә ярамый, киресенчә, үзеңнең яхшы күңелең, холкың, булдыклылыгың белән кешеләрнең күңелен яуларга кирәк. Чөнки игелек игелек булып, яманлык яманлык булып, иртәме-соңмы, барыбер синең үзеңә әйләнеп кайтачак.

Ә менә Гадиләгә килсәк, ул – риясыз, акыллы һәм ярдәмчел кыз. Суга батып исән калганнан соң, ул үзен чыннан да, Шөхрәткә бурычлы дип саный. Тик тора – бара бу бурыч котылгысыз бер бәлагә әверелә. Гадилә үзенең эчкерсез, саф күңелле дустын танымый башлый. Ул үзенең дустына өй эшләрен кучерүнең начар гамәл икәнен аңлатырга тырышып караса да, урынсыз була. Шөхрәт инде куркытып, янап күчерә башлый. Һәм Гадиләгә бурычын исенә төшерергә дә тарсынмый. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге була, дигән кебек, әлеге “дуслык”ка да чик куела. Ә бит кайчандыр алар аерылгысыз дулар иделәр...

"Ак тонбоек" повестенда Ф.Яруллин герой характерын бирү остасы буларак ачыла. Аның геройлары эштә, хәрәкәттә күренәләр, бер-берсенә охшамыйлар. Геройларның шәхси кичерешләргә бай итеп бирелүе повестьны уңышлы иткән тагын бер сыйфат дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Әсәрдә чорның, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең драматизмы да оста чагылдырылган; гыйбрәтле, сабак булырдай фикерләр дә күренеп китә. Бу әсәрдә бүгенге көндә дә гыйбрәт алырлык күренешләр тасвирлана.

"Ак тонбоек" повесте бүген дә кеше күңелендә матурлык уятучы әсәр булып кала бирә.

**Хәмитова Айгөл**
**Байкиев К.С. исемендәге Ишкурма кадет интернат-мәктәбе**
**Җитәкчесе-Гәрәфиева М.И.**

*Бәдретдин – минем яраткан әдәби героем*

Әмирхан Еники әсәрләре, бигрәк тә хикәяләре татар әдәбиятының йөзек кашлары саналырлык һәм санала да. Язучы иҗатының бер үзенчәлеге — тәрбиясе, затлылыгы белән аерылып торган кешеләрне үзәккә куеп тасвирлау, аларның рухи дөньяларын ачу. Ул герой турында баштан ук кистереп фикер әйтеп куярга яратмый. Әкренләп-әкренләп кенә, деталь арты деталь өстәп, тулы образ тудыра.

Беренче абзацтан соң ук без төп геройларның берсе булган Бәдретдин белән таныша башлыйбыз. Аның иң ярлы егет, кыенсынучан холыклы, кешегә салынмый торган икәнлеген беләбез. Кайдадыр тары ипие белән бер йомарлам май җибәреп ятучы әнисе барлыгы бер җөмлә белән генә әйтелеп үтелә һәм игътибарга да алынмый диярлек. Игътибар итә калсаң да, Бәдретдин үзе күзгә бәрелеп тормагач, әнисе бигрәк тә шундыйдыр инде, дип уйлап куясың.Бәдретдиннең үзен тасвирлау исә озынгарак китә. Һәр абзац аның аерым бер сыйфатыннан хәбәр бирә. Ул артык белемле, тырыш, сабыр, шигырьләр дә яза икән. Бәдретдиннең шигырьләре башкаларныкыннан гадилеге, тормышчанлыгы белән аерылып тора. Алар тирән фәлсәфә салынган шигъри парчаларга ошаганнар. Ә бит иҗатның сыйфатлары да кешенең яшәү, фикерләү рәвешенә, социаль чыгышына һәм башка бик күп нәрсәләргә бәйле була ала. Без әнә шулай дип уйлыйбыз. Болардан соң әдип, тагын да тәфсиллерәк итеп, табигать хозурлыкларын тасвирларга тотына. Әдәбиятны тоеп, вакыйгаларны алдан сиземләп укучы язучының болай эшләвенең, малайларның нечкә күңеллелекләрен күрсәтү өчен генә булмыйча, киләчәктә язылачак вакыйгаларда аларның үз-үзләрен тотышларын мотивлаштыру өчен дә кирәк икәнлеген аңлый. Егетләр, ниһаять, Бәдретдиннең авылына килеп җитә, атларын туара. Йортка узалар, егетнең әтисе, бабасы, йөз яшергән әнисе белән танышалар. Соң дәрәҗәдәге хәерчелектә дә чиктән тыш пөхтәлек саклап булганны күреп шаккаталар. Гаилә эчендә эчкерсез мөнәсәбәт яшәве дә сөендерә үзләрен. Беренче минутлардан ук аларда бу йортка карата җылы хисләр уяна. Бәдретдин әле моңарчы күренмәгән яклары белән ачылып китә: ул ярлылыкларыннан да, әнисенең кешегә күрсәтмәс ямьсезлегеннән дә оялмый, һәм хәтта, шул ямьсез әнисен кеше алдына чыгарып, аның өчен махсус көй уйный. Шушы өй, алардагы җан ияләре тудырган хисләргә аваздаш моңнарны ишеткәндә, бер-берсенә тирән мәхәббәт белән ачылып киткән ана һәм баланы күрү егетләрне телдән яздыргандай итә. Эчке дөньясының гадәттән тыш матурлыгы ханымның фаҗигасен тагын да көчәйтә. Хикәяләүче дә шул тәэсирләрдә яши башлый. Ананың, матурлыкка хаклы булып та, табигать тарафыннан кимсетелүе йөрәктә сагыш, нәфрәт, бушлык тудыра. Әсәр: «Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!» дигән юллар белән бетә.Бу хикәядә нигездә Бәдретдиннең әнисенең матурлыгы турында сүз барса да, без башка геройларның да эчке дөньясы турында уйлыйбыз. Бәдретдингә хас уңай сыйфатларның нигезе гаиләдә икәнлеге хакында нәтиҗә ясыйбыз. Үсмерне иптәш иткән, аны аңлаган, әнисен кызганган һәм ярата алган һәр егет күңелдә җылы хисләр уята.

Бәдретдин – идеал образ. Иң мөһиме – ул әти – әнисен, өлкәннәрне хөрмәт итә. “Ата – анасын зурлаган үзен зурлаган булыр”, ди халык мәкале. Бәдретдин образы миндә нәкъ менә шул сыйфатлары өчен дә соклану хисләре уятты. Тормышта Бәдретдин кебек затлар күбрәк булса, тормышыбыз күпкә җиңелрәк булыр иде.

**Гильманова Камилия**
**Түбән Кама шәһәре**
**инглиз телен тирәнтен өйрәнүле**
**33нче утра гомуми белем бирү мәктәбе**
**Җитәкчесе-ИсмәгиловаИ.И.**
**туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Минем яраткан әдәби героем –Ә.Еникинең “Кем җырлады ”хикәясеннән Таһирә образы.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды

Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Сарман буйларында тирәктә шул,
Сарман буйларында тирәктә.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
Үрелеп чәчәк ата йөрәктә.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә, чыннан да, яралы лейтенант егетнеңсөйгәне Таһирә иде.

Туган як көйләре белән егетнең соңгы сәгатьләрен якты нур белән балкыткан, күңелендә ләззәтле хисләр, истәлекләр, татлы хыяллар кузгаткан, калган тормышына ямь биргән , аның авыр хәлен җиңеләйтеп җибәргән.

**Хәкимханова Алия**
**Түбән Кама шәһәре 36нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**Җитәкчесе-Юнысова Гөлназ Рамировна**

*Таһирә - минем яраткан әдәби героем!*

Җәйге каникулның соңгы көннәрендә, берәр “тәмле” китап укып, ял рәхәтен озайту хисләре кичерәсем килде. Күңелгә ятышлы китап эзләп, авылдагы зу-у-ур шкафны кат-катактардым. Аяз Гыйләҗевның таушала төшкәнкитабын таптым. “Яра” әсәрен беренче тапкыр мин шул җыентыкта күрдем.

Авылда“ишегалды” дип атала торган җанга рәхәтбер җир бар. Безнең ишегалды гөлләргә күмелеп утыра, кырыйларда яшел чирәм үсә. Бакчабыздан сузылган алмагач ботагыннан шул үләнгә “шылт-шылт” килеп алма коела.

“Яра” әсәрен укырга керешкәндә, менә шул тирә-юнь рәхәтлеген тоеп,гап-гади бер хикәя кебек кенә укый башлаганым истә.Менә “Яра”дагы яшьләр Габдулла белән Зәйтүнә дә бер-берсен өзелеп ярата. (Төп образларның исемнәрен укыгач, “Әһә, Аяз Гыйләҗев Тукай белән аның Зәйтүнәсе исемен кушкан”, – дип уйлап куйганым истә.) Алар шул чордагы күп гашыйклар кебек, “Галиябану” спектаклендә Хәлил-Галиябану рольләрен уйныйлар. Матур җырлыйлар.(“Әһә, укучы күңелендә Габдулла – Зәйтүнә мәхәббәте Хәлил-Галиябану мәхәббәте белән тәңгәлләштерелә).

Сөләйман бабай, Зөлайха әбинең искиткеч сабыр холкына сокландым. Сугыштан соңгы газаплы еллар, шул чор яшьләренең язмышы, авыр яраланган Габдулла чиксез кызгану хисләре тудырды. Әсәрне укый торгач, Зәйтүнә дә Кәримҗанга кияүгә чыгып куя. (“...менәике гашыйк тормышында классик Исмәгыйль дә килеп чыкты...”).

“Яра” әсәре, укый барган саен катлауланып, үз эчтәлегенә суырып алып кереп китте.Гади хикәяләү кебек кенә башланган иде, хәлләр, вакыйгалар күз алдында җанлана башлады. Менә бу хисләр өчен кайбер әсәрләрне мин “көчле әсәр” дип бәялим.Ә “Яра” повестен, һичшиксез, Зәйтүнә образы көчле итә.

Тормыш – катлаулы. Сөйгәнен күпме дә көтәргә әзер Зәйтүнә, авыр тормыш шартларыннан изаланган анасына каршы килә алмый һәм яңарак сугыштан кайткан Кәримҗангакияүгә чыга. Кыз булачак иреннән дә, аның туганнарыннан да күңеленең Габдуллада булуын яшерми. Менә шуны яшермәве кызның нык рухлы, үз хисләренә тугры калырлык көчле шәхес булуын раслый.

Зәйтүнә әдәпле, итагатьле егеткә кияүгә чыкса да, җан тынычлыгы таба алмый. Яшь хатын барыбер сөйгәне Габдулланы сагынып, аның, кайтуын көтеп яши. Көннәрдән бер көнне хәбәрсез югалган Габдулла авылга кайтып төшә. Аның бөтен тәне, йөзесугыш яраларыннан нык бозылып беткән була, хәттаүз-үзен дә таный алмый.Тәмамгарипләнеп, җәрәхәтләнеп, бөкрәеп беткәнкартка охшаган Габдулланы авылда бары карт эт белән Зәйтүнә генә таный.

Зәйтүнә –иренә тугры хатын, малаен сөеп-назлап үстерүче ана. Акылы, эшчәнлеге, уңганлыгы белән зур, нык нәселдә хөрмәт казанган килен. Акыллы хатын тормышта туган авыр мәсьәләне үзенчә хәл итә. Ул Кәримҗан гаиләсенә барысын да әйтеп-аңлатып, улын алып, Габдуллаларга күчә. Әлбәттә, Зәйтүнәне әлеге адымга күндерүче хис – олы мәхәббәт. Хатын бу мөһим адымы өчен мәхәббәттән көч алгандыр... Менә шул рәвешле, әсәр башындагы гади генә Зәйтүнә, үзенең һәм якыннарыныңтормышын үзгәртә алырлыккөчле характерлы, үз фикере нык булган ихтыярлы шәхескә әйләнгән.

Көчле әсәрләр сирәк очрый, алар күңелдә көчле хисләр уяталар. Зәйтүнә образы минем өчен – соңгы елларда укылганнардан,күңелдә калган, соклану хисләре уята алган әдәби герой.

... Теге көнне, җәйге каникул ахырында, “Яра” әсәре бер кичтә укылды. Чәчәкле ишегалды да, яшел чирәмгә коелып утыручы алмалар да онытылды. Күңел озак кына, барысы да бергә җыелган Сөлайман картларның ишегалдында йөрде кебек...

**Хөсәйнов Ильяс Ирекович,**
**Кама Аланының аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 2нче урта мәктәбе**
**Җитәкчесе- Хөйруллина Лилия Аркадьевна,**

«Йомшак кынаҗәйгеҗил исә.Далабуйлапкылганнарйөгерә,кылганннарйөгерә…

...Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән,алъяпкыч бәйләгән,күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык бер әби кизәк җыеп йөри...”Татар әдәбиятына без яраткан,без олылап искә алган,хөрмәтләгән Акъәби әнә шулай килеп керә.

ӘмирханЕникинең “Әйтелмәгән васыять” хикәясендәге әдәби герой-Акъәби, минем яраткан героем.Аксылу,Аккилен,Акҗиңгә, Акъәби-гомере узган саен шулай төрлечә атыйлар бу башкорт карчыгын. Гомер буе пакъ күңелле, намуслы,саф җанлы булган ул. Авылыннан, туган җиреннән аерылмаган,хезмәт белән көн күргән, мал-туар, кош-корт асраган,ире белән балаларын тәрбияләгән,аларга югары белем бирә алган. Менә хәзер балалары кайсы кая таралып,заманча яшәп, зур җирләрдә эшләп, шәһәр кешеләре булып беткәннәр.Алар буыннарны ялгап торган җепне югалтканнар,авылга да бик сирәк кайталар, аналарының авылын сагынуын да,аның теләген дә,сагышын да аңламыйлар.

Ананың балаларының авылдан чыгып китүләренә, туган туфрактан читләшүләренә җаны сыкрый.Җитмәсә, олы улы Суфьян рус кызына өйләнгән.Әби моны башкорт

халкыннан йөз чөерү,нәсел-ыруыннан читләшү дип саный.Дөрестән дә,оныклары белән әби сөйләшә алмый, чөнки алар башкортча белмиләр. “Аһ,бу тел юклыгы!”. Акъәби балаларына газиз туган телне күз карасыдай кадерләп сакларга кирәк дип васыять әйтеп калдырырга тели.Ләкин васыятен киләчәккә җиткерерлек буыны юк...
Акъәби-иң кешелекле,иң шәфкатьле, бала җанлы,балаларына ихлас күнелдән тәрбия биргән хезмәт сөючән кеше.Ул гомере буена хәләл көче белән яшәгән.Җиргә килеп,гомер чигеп, кешеләргә гел изгелек кылып,авылдашларының күңелендәһәрвакытАк күңелле - Аксылу,Акъәби булып кала.

Тормышта Акъәбигә охшаш шәхесләркүп.Акъәбине уйлаган саен күз алдыма үземнең милли җанлыәбиемкилеп баса.Без, Акъәбинең оныклары,һәрчак җылы карашыбызны кызганмаска,исәннәрнең кадерен белеп,үз туган телебездә сөйләшеп,милләтебез белән горурланып яшәргә тиешбез.Халкымны сөям мин,аның үткән данлы тарихы белән горурланам,ак әбиләр алдында баш иям.

Ходайның һәр бирмеш көнен
Дога кылып сәламлиләр.
Ил шатлыгы, ил аклыгы-
Ак яулыклы ак әбиләр.

**Абдрахимова Айгөл, Питрәч районы Ф.А.Сафин исемендәге Шәле урта мәктәбе 8класс**
**Җитәкчесе – Замалеева Т. С. татар теле укытучысы**

МинТуфанМиңнуллинның күп кенә әсәрләре белән таныш. Шул әсәрләрарасында миңа ошаганы – “Өлдермештән Өлмәндәр” әсәре. Иң ошаган образ – Өлмәндәр карт.

Өлмәндәр Өлдермеш авылында тыныч кына яшәп ята. Яше туксаннан артса да әле ул “җир җимертеп” яши. Үзенең шаян сүзләре белән кешеләрне көлдерә, аларның күнелләрен күтәрә.

Бу әсәрнең төп темасы – яшәү. Яшәү нәрсә соң ул? Минемчә, яшәү ул – АллаҺ тәгаләгә буйсыну, кешеләргә кулыңнан килгәнчә ярдәм итү, матур гына тормыш алып бару.

Өлмәндәр карт нәкъ шулай эшли дә. Ул һәрбер кешегә игелек кенә эшли. Әмма аңа тыныч кына яшәп ятарга туры килми. Аның янына Әҗәл килә, ләкин Өлмәндәр карт җебеп төшми, киресенчә, очрашкач тагын да яшисе килә башлый. Алар арасында көрәш башлана. Өлмәндәр хәтта Әҗәлне дә җиңә. Ничек итеп дисезме? Ул Әҗәлне тормышта ничек яшәргә кирәклегенә төшендерә.

Өлмәндәр карт белән очрашкач, “Яшәү- нәрсә ул? Кеше ничек яшәргә тиеш?” дигән сорауларга җавап эзләдем һәм мондый нәтиҗәгә килдем: яшәү ул, беренче чиратта, кешеләргә игелек эшләү, башкалар бәхете өчен үзеңне җаваплы итеп исәпләү, дөньяда кешеләргә бары тик яхшылыклар гына кылу....Өлмәндәр образыаша автор безгәтормыш юлын ничек үтәргә кирәклегенүрнәк итеп куя.Әгәр дә һәрбер кеше Өлмәндәр карт кебек изге күңелле булса, тормышыбыз тагын да ямьләнер,яшәвебезнең мәгънәсе артыр иде.Аның күңел матурлыгы барыбызны да таң калдыра.Кешенең гомере үлгәч тә озын булуын теләсәк, һәрвакытта да кешеләргә игелекләр генә кылып яшәргә кирәк

**Фазлиева Лилия Ришатовна, Питрәч районы Пановка төп белем бирү мәктәбе**
**Җитәкчесе – Чернова Н.И. туган тел һәм әдәбият укытучысы**

«Минем яратканәдәби героем-Галия». Г.Кутуйның “ Тапшырылмаган хатлар”повесте.

Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумдым, шатлык дулкыннарында йөзә башладым. Чынлап та, корып, саргаепбеткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү — охшашы булмаган матурлык бит. Үземне, гомумән, кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да, ләкин минем хәл ул чагында шуңа бик якын иде.

Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында — Ялгашта тудым. Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин — аның кызы — Москвада тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуны күрдем... Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телендә кирәгенчә белмәгән. Ә мин — аның кызы — татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүдә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин — Чулак Фәхри кызы — хәзер үзем доктор.

Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң киң сулыш алып эшләү шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен. Миңа әле күптән түгел бер яңа роман укырга туры килде. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк, иске заман бизгәгендә, җәфа чигү утында яшәгән нәсел.

Искәндәр!Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк! Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый.

Бу музыкада сагыну моңы да, ярату-яратмау тавышы да, җил-давыл да — бар да бар. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясеа еруча матур яңгырый.

Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа җылы рәхмәт яусын.

## “9-11нче сыйныф укучылары” категориясе
## “Мин бу шәхескә сокланам”

**Рәхимова Дина, Яңа Чишмә авылы гимназиясе 9 а сыйныфы**
**Җитәкчесе: Шакирҗанова М.М., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

*« Җилкәннәр җилдә сынала» Ф.Яруллин*

Алтыннан кече түгел мин,
Ипидән олы түгел.
Үлемнән көчле түгел мин,
Тик язмыш колы тугел.

Тормыш гаделлектән генә тормый. Кемгәдер бәхет өеп бирелә, бар тормышы диярлек ак төсләрдән генә тора. Ә алар аның кадерен белмиләр: зарланалар, юк өчен дә кайгыга чумалар. Икенчеләрне язмыш зур сынаулар алдына куя. Беренче карашка, көч җитмәслек, кеше күтәрә алмаслык авырлыклар белән сыный.

Фәнис Яруллин-үз бәхетен әнә шулай кыенлыклар белән тапкан кеше. Аның әсәрләрен укыганнан соң хәйран каласың. Нинди генә темаларны яктыртмаган да нинди генә сорауларга җавап эзләмәгән ул аларда. Күңелдә бер сорау туа: гомерлеккә урын-җиргә бәйләнгән кеше ничек бездән мең тапкыр күбрәк күргән икән? Ничек дөньяның бөтен нечкәлекләрен дә тоя, аңлый белгән икән?

Ул бит әле аңлап кына калмый, кешеләрнең җаннарына, йөрәкләренә үтеп кереп, тетрәндерерлек итеп яза да белә.

Чыгышымны бүгенге авыр, катлаулы заманда һәр кешенең яшәү девизы булырдай, Фәнис абыйның тормыш тәҗрибәсеннән алып язган сүзләре белән тәмамлыйсым килә: “Язмыш синең тез астыңа китереп сукса-егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса-үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа-күбек булып өскә күтәрелмә, асылташ булып төпкә бат, ялтыравыкны куреп чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә- яңгыр тамчыларына кушылып, җиренә төш. Җилкәнеңне җилләр екса-йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә ала. Түземлеләр генә бәхеткә лаек.”

**Ризатдинов Рамис,**
**Сарман Аграрколледжы**
**2нче курс студенты**
**Җитәкчесе – Нәҗметдинова Ч.М., татар теле укытучысы**
**Авторы: Ризатдинов Рамис**

**Гомере аның моңлы бер җыр иде...**

“Гомерем минем моңлы бер җыр иде...”
Диеп язган гомере туырнда.
Кемнәр шулай җырлап үтәр икән,
Хәтта данлы көрәш кырын да.

Яшәү белән үлем арасында,
Ахырын белмәс күпме көн уза.
Юк, ул ятмый бары үлем көтеп,

Яшәү бөек – шуңа көч таба.

Әсирләрнең күңелендә азатлыкка,
Өмет чаткылары кабыза.
Җыр ярдәме белән барысы да,
Мәхәббәте белән, туган ягына.

“Гомерем минем моңлы бер җыр иде...”
Исеме дә җырга әйләнгән,
Онытылмас мәңге аның ис(е)ме,
Көчле рухы – дөнья тетрәткән.

Үлем аша атлап үлемсезлеккә,
Җәлилчеләр белән берлектә.
Дошманга да каршы шул җыр белән,
Үлгәндә дә җырлап үлделәр.

Мәңге калыр алар батырлыгы,
Шигырьләре барыбыз сокланган.
Исемнәре халык хәтеренә,
Мәрмәрләргә уелып язылган.

**Зиннәтуллин Сәйдәш,**
**Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче гомуми утра белем бирү мәктәбе, 11А сыйныфы**
**Җитәкчесе – Борһанова М.Ф., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Мин бәхетле, чөнки минем янәшәмдә әтием дә, әнием дә бар. Мин пар канатлы гаиләдә тәрбияләнәм. Һәм шуның белән горурланам. Әйтегез әле: кем горурланмас шундый гаиләсе белән!

Мин әниемне өзелеп яратам. Тик бүген әтием турында бер-ике сүз әйтәсем килә.

Әткәй! Син бит, иң беренче чиратта, әниемнең таянычы. Нинди генә авырлыклар килсә дә,сез әнием белән икәүләп, чыгу юлларын эзлисез. Эштән арып-талып кайтсаң да, минем хәлләрем, укуларым белән кызыксынасың. Ялгышларым булса, шундук төзәтергә мөмкинлек бирәсең.Һәрвакытта : “Укы, укуың үзең өчен, ”- дисең. Укыган кеше генә, үз максатына ирешә ала шул. Мин моны апаларга, абыйларга карапәйтә алам.Шуңа күрә тырышып белем алырга тырышам. Өйдә картина төшсә дә, шкаф ишеге ватылса да, урындык селкенсә дә, краннан су агып торса да, лампочка янмаса да,без сиңа таянабыз. Чөнки бу эшләрне әлегә син генә эшли аласың.Син кыю йөрәкле, курку белмәс. Әтием, мин сиңа сокланам!

Сокланам мин сиңа! Була бит шундый кешеләр: күзләреннән дә, үзеннән дә яктылык, нур бөркелеп тора. Андый кешеләр белән очрашканнан соң үзеңдә бетмәс-төкәнмәс көч, яшәү дәрте тоясың. Минем әтием дә шундыйлардан.

Әтиемнең исеме - Фәнис. Үзе кап-кара, үзе чибәр. Елмаеп җибәрсә, дөньялар яктыра төсле. Ул йөк машинасында йөртүче булып эшли. Төзелеш материалларын ташый ул. Иртәдән кичкә кадәр руль артында. Күзләре дә, куллары да таладыр, мөгаен. Әтием,киләчәктә миндә синең кебек үрнәк булырга тырышырмын, синең ышынычыңны аклармын.

Яшәү өчен ышанычлар бирдең,

Өйрәттең син белгән кадәрен.
Алар кебек һичкем якын итмәс.
Белик әтиләрнең кадерен!

**Шакирова Айгөл,**
**Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче гомуми утра белем бирү мәктәбе, 9 б сыйныфы**
**Җитәкчесе - Каюмова Р.Ф., туган тел һәм әдәбият укытучысы**

Әнием! Исләремә сине төшерсәм дә,
Үз көчемә үзем ышанам.
Күз алдымда синең нурлы йөзең.
Мин, әнкәем, сиңа сокланам!

Үземнең язмамны шушы шигырь юлларыннан башлап җибәрәсем килә.

Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, беренче әйткән сүзләреңне ишетеп сөенгән,тәпи атлап китүеңне күреп шатланган. Ул безне туган телебезне яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны алардан башка күзалдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме, шатлыгы.

Һәркемгә үзәнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үзәнием бик кадерле. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әннә", әни" сүзе белән ачылган. Әнием минем бик сабыр, тыйнак кеше. Әниемнең исеме - Раушания.Буисем фарсы теленнән килеп кергән.Ул: «Нуриясе; нур сибүче, нур чәчеп торучы; якты» дигәнне аңлата. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Әнием миңа дәресләремне эшләргә дә булыша: аңламаган сорауларыма да сабыр гына җавап таба, файдалы киңәшләрен дә бирә.

Мин мәктәптән кайтуга, өйдә тәмле ис таралган була. Әнием инде тәмле-тәмлеризыклар пешереп куярга дә өлгергән!Без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребезбеләнуртаклашабыз. Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән "кызым" диеп сөеп уята.Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар!Әнием, мин сине бик яратам! Сиңа иң изге теләкләремне генә телим.

**Сидорова Алина,**
**Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, «Гулькино төп белем бирү мәктәбе» 9Б сыйныфы укучысы**
**Җитәкчесе-татар теле укытучысыЧекашова Галина Федоровна**

*«Таланты алдында баш иям»*

...Бик еш искә алам мин аны. Тукай дисәң дә янәшәсенә Галиәсгар абзый килеп баса. Габдулла Кариев дисәң дә — ул. Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев һәм татар әдәбияты, драматургиясе, театры сәнгатенең нинди генә күренекле эшлеклесен хәтергә алсаң да, янәшәләрендә, аларның һәркайсы беләк якын аралашып яшәгән, табигате белән бик мөлаем дә, яхшы ук кырыс та булган Галиәсгар Камал тора. Димәк, халкыбызның киң

тармаклы культурасы белән нык үрелеп яшәгән, аның үсешендә зур роль уйнаган кеше ул. Улинде бу вакыт Татар театр техникумын тәмамлап, беренче чыгарылышта режиссер-дипломант буларак, «Хезмәткә мәдхия» пьесасын һәм Татар дәүләт академия театрында эшли башлап,режиссер буларак үзенең ике сатирик комедиясенһәм Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен сәхнәләштергән иде. Г.Камал — татар милли театрын үстерү эшенә зур көч куйган шәхес. Ул, театр репертуарын драма әсәрләре белән баетудан тыш, «Сәйяр» труппасында артист һәм режиссер булып та эшли. Татар театры тарихында актерлар династиясен башлап җибәрә: энеләрен һәм сеңлесен сәхнәгә алып килә. Соңрак улы Әнәс тә драматург, сәләтле режиссер һәм артист булып китә.Димәк, үзе дә театр дөньясына борын төртеп килә торган бер яшь кеше иде. Көннәрнең берендә, ул чорда яхшы ук нык танылган, аның пьесаларына һәм сәхнәгә куйган спектакльләренә рецензияләр язган журналист Мөхәммәт Парсин белән бергәләп «Кызыл Татарстан» редакциясенә килеп керделәр. ук зур гына бүлмә — зал. Галиәсгар абзыйның «мөгез чыгаручы егет» дигән сүзе һәм шулай күз кырые белән генә сөзеп карап куюы реалистик театрга тел тидергәнем өчен аның шелтәләве кебек тоелды миңа. Бу минутларда башымнан төрле уйлар кичте. Хыялында элек күз алдына йөрткән мәһабәт гәүдәле, озын мыеклы атаклы драматург Галиәсгар Камал кинәт кенә юкка чыкты да, аның урынына кырыс кына табигатьле, тәбәнәк кенә буйлы, башкалардан бер ягы белән дә аерылмый торган гади генә кеше утырып калды.

Галиәсгар абзый үз өстәле янында утырып калды.Аның башына тагын кызык кына уй килде. Шундый зур талант, атаклы әдип-драматург, ә үзе гади генә эш эшләп, әдәби сотрудник вазифасын үтәп, редакциядә утыра. Ни өчен? Хәер, әнә бит ул нәрсә ди, реаль тормыш, халык, реалистик сәнгать... Ә газета әдипне реаль тормыш белән, халык белән бәйләгән иң зур чараларның—арадашчыларның берсе түгелмени?

Шушы беренче тапкыр очрашып танышудан соң Галиәсгар абзый белән исәнлек-саулык сорашып уза торган булдык.

1928 ел. Кыш. Качалов исемендәге Зур драма театрының фойесы. Бу көннәрдә әле монда Татар дәүләт академия театры урнашкан иде. Минем Ленинградта, Сәнгатьләр Тарихы Институтының театрны өйрәнү бүлегендә укыган чагым. Театрда нинди спектакль баруы төгәл генә хәтеремдә калмаган. Тәнәфес вакыты. Фойеда Галиәсгар абзый миңа аркасын куебрак баскан бер кеше белән җанлы гына әңгәмә алып бара. Әлбәттә инде мин, ерактан кайткан студент, Галиәсгар абзый белән күрешми уза алмадым.

- Исәнмесез, Галиәсгар абзый,— дип аңа кул бирдем. Ул мине ачык чырай белән каршы алды, кулымны кысып күреште һәм янында торган мәһабәт гәүдәле, кара мыеклы кешегә тәкъдим итеп:

- Таныш бул, Сәгыйть, бу безнең өметле генә яшь драматургыбыз һәм режиссерыбыз, Театр техникумын тәмамлап бер ел театрда эшләгәч, без аны Ленинградка, югары белем алырга җибәрдек. Институтка. Атаклы театр эшлеклеләре һәм галимнәреннән сабак алырга.

Кыскасы, булган егет, чибәр егет. Ул аның янындагы кешенең йөзенә күзен төшерде. Күзен төшерде һәм... шатлыктан тетрәнеп үк куйды. Йа хода! Бу бит Сәгыйть абый Сүнчәләй. Аның укытучысы. Сәгыйть абый үзе дә кычкырып көлеп җибәрде һәм аны кочып алды.

- Бу уңган, чибәр егетне ул үзе, дөресрәге, Шәриф абый белән икәүләп, менә мондый бала чагыннан ук әле (ул кулы белән идәннән әз генә калкурак ара ны күрсәтте), колакларыннан тарта-тарта, ал сабакларын да, арт сабакларын да укыта-укыта үстердек. Ә, Риза? Шулай түгелме әллә?

- Әйе, дөрес, нәкъ шулай, Сәгыйть абый. Минем әз-мәз әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәтебар икән, иң башлап моның өчен улШәриф абый белән аларгабурычлы— диде. Бик кыска гына итеп булса да, ул аларга Ленинград театрлары һәм андагы спектакльләр

турында сөйләде. Галиәсгар абзыйны иң кызыксындырганы ул елларда атаклы режиссер-педагог Александр Иванович Брянцев тарафыннан төзелеп, киң җәмәгатьчелек тарафыннан күтәреп алынган Яшь тамашачылар театры – “Театр юиых зрителей”(ТЮЗ) булды.

- Балалар өчен махсус театр, Яшь тамашачылар театры безгә дә кирәкбик кирәк. Яшьләрне тәрбия итүдә аның роле зур булачак,— диде Галиәсгар абзый. Театрның гына түгел, культурабыз үсеше белән дә, шулай ук халкыбызның гомуми язмышы белән дә бу ике әдипнең кызыксынулары аңа бик аңлашыла иде. Татар дәүләт академия театрының да әлегә махсус үз бинасы булмавы өчен борчылуы да нык хәтердә. Сәгыйть абый Сүнчәләйнең:

- Борчылма, Галиәсгар, балалар өчен театр да, үткән елда гына Академия исеме алган шушы дәүләт театрыбызның да үзенә атап салынган махсус бинасы булыр,— диюгә, Галиәсгар абзый: сәхнәгә куелып, тамашачы тарафыннан яратып, хуплап каршы алынган комедия. Пьесаның сәхнәгә һәр куелышында тамашачыга нинди дә булса яңа сүз әйтергә, әсәрнең фикерен тагын да тирәнәйтә төшеп, тамашачыга аны яңа ягыннан ачарга кирәк. Яналык ул — театрның төп таләпләреннән берсе. Бу очракта да театр өстенә төшкән төп бурычларның берсе шул иде, билгеле. Әсәрне тагын да кызыклырак, тамашачыга үтемлерәк итү ниятеннән чыгып, Кәрим абый текстка берникадәр өстәмәләр, кыскартулар, үзгәрешләр керткән иде. Алар турында ул коллегия утырышында артык тәфсилләп сөйләп тормады. Ләкин утырыштан соң, икәүдән-икәү генә калгач, нинди үзгәрешләр кертәчәге турында миңа бик җентекләп сөйләп бирде һәм нәтиҗә ясап әйтте:

- Башка авторның әсәре булса, бу турыда сөйләшеп тору да кирәк булмас иде. Ләкин бит «Банкрот» Галиәсгар абзый Камал әсәре. Төрле сәхнәләрдә куелып зур сынау үткән яхшы әсәр, яхшы комедия. Шулай булгач, безнең бу үзгәртүләрне... Кәрим абый белән әңгәмә озакка сузылмады. Бик тиз аңлаштык, килештек һәм Галиәсгар абзыйны театрга чакырып сөйләшергә дигән фикергә килдек. Икенче көнне Галиәсгар абзый Камал театрда, безнең яныбызда иде инде. Билгеле, без бу олы талантны нәүбәттә сәхнәгә куела торган пьесаның авторы итеп кенә түгел, ә театрның нигезен салучыларның берсе һәм иң күренеклесе итеп хөрмәтләп каршы алдык. Ул бик кыска гына итеп Галиәсгар абзыйга «Банкрот» комедиясен сәхнәгә куярга планлаштыруын, бу җаваплы эшкә режиссер итеп Кәрим абый Тинчу-ринны билгеләвен, аның бу спектакльне бүген ничегрәк сәхнәдә яңратырга теләве, оформлениенең художнигы кем, кайсы рольне нинди артист башкарачак— кыскасы, барысын да сөйләп бирде. Галиәсгар абзый аның сүзенигътибар белән тыңлап утырды да:

- Бик хуп, барысы да урынында. Рольләр, минемчә, бик дөрес бүленгән. Декорация дә эшләнер, кием-салым да табылыр. Кәрим инде ул оста режиссер, шулай булгач, бары да урынында булыр дип ышанам,— диде.

- Боларның күбесе бит инде авторның катнашыннан башка, режиссер үзе эшли ала торган төзәтмәләр. Авторның рөхсәте һәм катнашыннан башка, дигән суз. Әсәрнең төзелешенә дә, образларның асыл сыйфатларына да, иң мөһиме — пьесаның әйтергә теләгән төп фикеренә дә зыян китермиләр. Театрда чыгарыла торган спектакльгә сез хуҗа. Ә менә әсәрне бастырып, китап итеп дөньяга чыгарганда, мин — автор хуҗа. Бүген сезгә миннән фатиха, тулысынча ризалык,— дигән сүз чыкты.

Драматургиябезнең атаклы ветеранының хәтере калудан бик курыккан иде. Бүгенге очрашуыбыз һәм җаваплы эшебезнең шулай җиңел һәм көткән нәтиҗә белән тәмамлануына нык шатланды. Күреп тора, Кәрим абый Тинчурин да бик канәгать. Йөзендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю, күзләрендә ялкын. Үз эшеннән канәгатьләнү тойган чакларда һәрвакыт диярлек шундыйрак кыяфәттә була ул.

**Садеев Ислам Ирекович**

**Түбән Кама шәһәренең 14нче гомуми белем бирү лицее**
**Җитәкчесе- ГилмуллинаГөлияРашатовна**

Тормыш, яшәү – үзеберолымогҗиза бит ул. Яши-яшикешеәнәнәкъшуңаныграктөшенәдә. Елдан-ел күпнәрсәләрнеңмәгънәсен, серен тирәнтенрәкаңлап, яшәүкадерендәкүбрәкбеләбашлыйсың.Авыртормыш юлынүтү, төрле авырлыкларны җиңү, кешене тагын да көчлерәк, яхшырак булырга этәрә. Нәкъ менә шундый,башкаларны үз артыннан ияртеп, әйдәп баручы кешеләр генә беренчеләрдән була ала.Беренче булу бервакытта да җиңел түгел. Шулай да нәкъ менә беренчеләр, кабатланмас булып, тарихта үз урыннарын алалар һәм милләт хәтерендә калалар.Әлеге кешеләр белән горурлану, киләчәк буында шундыйшәхесләргә карата горурлык хисләреуяту, безнең бурычыбыз түгелмени? Әлбәттә бу минем һәм халкымның бурычы.

Кем сон ул? Минтимер Шәймиев - хәзерге Татарстан Республикасын оештыручы, бөек тарихлы татар дигән милләтнең горур исемен дөнья күләмендә ишеттерүче.

Минтимер Шәймиевның президентлылык еллары белән генә түгел, балалык еллары белән үк горурланырга мөмкин. Кечкенә Минтимирнең балалык еллары сугыштан сонгы авыр чорларга туры килә. Шуңа карамастан ул безнен күбебез тыныч тормыштада ирешә алмаган үрләргә менеп җитә алган.1954 елда М.Ш.Шәймиев мәктәпне тәмамлый һәм Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Казан авыл хуҗалыгы институтының механикалаштыру факультетын тәмамлаганнан соң, 22 яшендә үк баш инженер булып эшли башлый. 1991 елга кадәр күп кенә җаваплы,дәрәҗәле урыннарда эшли.Ә инде1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасының беренче Президенты итеп сайлана.Президент булу-бик җаваплы, сүз дә юк. Ләкин гади авыл егете монда да югалып калмый, ике мәртәбә (1996 елның 24 мартында һәм 2001 елның 25 мартында) ул яңадан Татарстан Республикасы президенты итеп сайлана.

Әйе, мин чын-чынлап әлеге шәхес белән горурланам. Бу конкурста татар секциясен сайлавымның төп сәбәбе дә шул. Чөнки Минтимир Шәрип улы Шәймиев рәхмәте белән безне таныйлар, фикерләребезгә колак салалар, исәпләшәләр. Без аяк терәп: “Мин - татар!..” дип горурланып әйтәбез, рәхәтләнеп, туган телебездә аралаша алабыз. Минтимер Шәрип улы - үзен бөтенләе белән туган милләтенә, республика халкына багышлаган шәхес.Республика җитәкчесе булып егерме ел буе эшләвенең иң зур казанышы - халкыбызның дәрәҗәсен күтәрү, татар милләтенә тискәре карашны Рәсәй һәм дөнья күләмендә тамырдан үзгәртү булды.

Мин бу шәхеснең президентлылык итү еллары белән генә түгел, соңгы елларда башкарган эшләре белән дә горурланам.Бүген дә ул ватаныбызның киләчәге ышанычлы һәм якты булсын дип яши. “Яңарыш” фондын оештырып, борынгы Болгар, Зөя шәһәрләрен төзекләндерү кебек олы эшне башкару моны аермачык күрсәтеп тора... Үзенең интервьюларының берсендә, Минтимир Шәрипови болай диде:

“ Үз милләтебезне сакларга һәм үстерергә, туган җирне яратырга. Бу - милләткә хезмәт итү дип атала. Бервакытта да шуны онытмаска кирәк: үзебезгә кирәген үзебез эшләргә тиеш, аны башкалар эшләмәячәк. Милләтебезне, телебезне саклау, аны үстерү, халкыбызның үзаңын киләчәктә дә югарыга үрләтү - ул без башкарырга тиешле гамәлләр. Ә без булдырабыз! Үзебезнең язмышны үз кулыбызга алып, соңгы елларда ирешкән уңышларыбыз моны дәлилләп тора.” Мин бу сүзләр белән тулысынча килешәм һәм горурланам. Зур сәхнәләрдән әлеге шәхес турында сөйләү, минем өчен –горурлык.

**Нуриәхмәтова Лилия,**

**Түбән Кама шәһәренең**
**14 нче гомуми белем бирү лицее**
**Җитәкчесе - Абуярова Сәмәрә Миннефаил кызы**

***«Сәнгать аның өчен һәрвакыт олы шатлык»***

*Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,*
*Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.*
*Театр-яктылыкка, нурга илтә,*
*Кире юлга җибәрми, уңга илтә.*

Шулай дип язган бөек шагыйребез ГабдуллаТукай1907 елда.Әйе, театр – сәнгатьнең иң гүзәл төре, дияр идем мин дә. Ул кешеләрне көлдерә дә, елата да, уйландыра да... Без бүгенге тормышыбызны театрдан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Чөнки театр – тормышның көзгесе.

Бүгенге көндә татар театрының дәрәҗәсе турында бик күп фикерләр ишетергә була. Театрның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында бәхәсләрне телевидение аша күрергә, матбугат чаралары аша тыңларга мөмкинлекләр зур.Театр тарихы, аның башлап йөрүчеләре турындагы белемнәр мәктәп программасында да урын тапкан. Театр-безне яшәргә, фикер йөртергә өйрәтә, аннанэстетик ләззәт алабыз. Үткәнебез, киләчәгебез турында фәлсәфи уйларга этәргеч тә бирә ул безгә.

Мин дә бүгенге чыгышымныкабатланмас талант иясе, Россия Федерациясенең атказанган артисткасы, Татарстан Республикасы халык артисткасы Исламия Мәхмүтовага багышлыйм. Чөнки минбу шәхескә сокланам, аның иҗатына гашыйкмын.

Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтова менә 50 ел инде тамашачыларны сокландырып, моңландырып, рухландырып яши. Ул үз тамашачылары күңеленә ачкыч тапкан, моңлагән йөрәкләрне сөендергән, шатландырган олы сәхнә остасы.

Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтова 1943 елның 1 декабрендә Татарстанның Әлки районы Югары Әлки авылында туа.Урта мәктәпне тәмамлагач, 1963 елда Казанга килә һәм Татар дәүләт республика күчмә театрында бутафорчы, кассир булып эшли башлый. Аллаһыдан бирелгән таланты һәм бетмәс-төкәнмәс тырышлыгы аркасына театрның алыштыргысыз артистына әверелә.

Акча да, ир дә кирәкми, театрга гына эшкә алыгыз, дип килеп керә ул сәнгать дөньясына. «Аллага шөкер, барысы да булды; акчам да, яраткан, терәк булырдай ирем дә, иманлы газиз балаларым, хәзер инде оныкларым да бар», – дип шөкрана кыла Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Исламия ханым Мәхмүтова.

“- Артистка булу минем балачактагы хыялым иде. Әле ул вакытта артистны беркайчанда күргәнем булмаса да, укытучым Гариф абый Наврозовка “артистка булам ” дип җавап бирдем. Атаклы артист Галия Булатованың безнең нәселдән булуы да үзен сиздергәндер. Гаиләдә җиде бала үстек. Бер-беребезне тәрбияләдек. Бәләкәй чактан ук бик шук, чая идем. Караңгы базга төшеп каймак ашаган чакларым да булды ”, – дип искә ала Исламия Мәхмүтова.«Әнием мине «батыр йөрәкле» дип атый иде. Шуклыгым аркасында артист булдым дисәм дә була. Җырла дисәләр, җырладым, бие дисәләр, рәхәтләнеп тыпырдадым. Шулай итеп артист булдым мин.»

– «Мин бик бәхетле театрымда. Берсеннән-берсе кызыклырак, эшләр өчен авыррак рольләр насыйп булды миңа. Үз яшьтәшләремне, замандашларымны сәхнәдә гәүдәләндерү, шуның белән тамашачыны рухландыра алу – моннан да ләззәтлерәк бәхет бармы икән дөньяда?!»– ди ул.

Исламия Мәхмүтова 50 ел эчендә йөзгә якын төрле пландагы образлар иҗат итте. Болар - шат күңелле Смеральдина һәм җитди Беатриче (К.Гальдониның “Ике хуҗаның хезмәтчесе”), байлык дип авыз суын корыткан Гөлбану (Н.Исәнбәтнең “Хуҗа Насретдин”ы), тыйнак Мария (М.Сторожеваның “Гөнаһлы хатын”ы), күпбалалы ана Шамилә (Т.Миңнуллинның “Без бит авыл малае”), Беатриче (В.Шекспирның “Гаугалы мәхәббәт”е),

Шамсекамәр (М.Әблиевнең “Шәмсекамәр”е) һәм башкалар. Ә менә Ясминә (И.Юзеевнең “Кыр казлары артыннан”), Койтымбикә (Н.Фәттахның “Итил суы ака торур”), Ана (Ш.Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге”) һәм Кураж ана (Б.Брехтның “Кураж ана һәм аның балалары”) кебек эчке яктан тирән, үтә бер төгәллек белән тудырылган образлары — Татарстанның халык артисткасы, Россия Федерациясенең атказанган артисткасы Исламия Мәхмүтованы иҗат биеклегенә күтәреп, аны киң диапозонлы һәм тулы канлы, үзенчәлекле һәм профессиональ яктан югары дәрәҗәдә камил булган артистка итеп танытты.Илле ел дәверендә Исламия Мәхмүтова театр белән берлектә Россиянең бик күп төбәкләрендә гастрольләрдә дә булды. Аның иҗатына гашыйк тамашачылар Татарстанда гына түгел, Караганда, Ташкент, Бохара, Алма-Ата, Сәмәрканд, Бишкәк, Сургут, Нижневартовск, Томск, Ижевск, Уфа, Мәскәү кебек шәһәрләрдә дә бихисап.

Исламия Мәхмүтова — киңкырлы талант иясе. Ул үзен режиссерлык өлкәсендә дә, драматургия өлкәсендә дә уңышлы сынаган артистка. Хәзерге вакытта театр сәхнәсендә аның “Мәхәббәт чишмәсе” һәм “Күрәсем килгән иде...” спектакльләре зур уңыш белән бара.

Аның турында халык язучысы Гариф Ахунов: “Исламия Мәхмүтованың чыгышын күзәткәндә - драмтеатр сәхнәсендәме ул яки эстрададамы - сәнгатьнең аның өчен һәрвакыт олы шатлык икәнлегенә торган саен ныграк төшенә барасың”, - дип язып калдырган.

## «Укытучылар»категориясе
## «Минем остазым»

**Түбән Кама шәһәре 32нче гимназиянең туган тел һәм әдәбият укытучысы**
**Масаллимова Мәүлия Минвәли кызы**

Кайгы килгәндә дә, егет бул, ди
Шул остазлар безне өйрәткән.
«Укытучы» белән «әнкәй» сүзе,
Бергә саркып чыга йөрәктән.

Иң игелекле һөнәр нинди дисәләр, һич тә шикләнмичә, укытучы дип әйтер идем мин. Дөньяны танып белү, укырга- язарга өйрәтүдән тыш, акны – карадан, яхшыны яманнан аеру, изгелекне өстен күрү, нинди генә кыен хәлдән дә чыгу юлларын табу хикмәтләрен безгә остазларыбыз төшендерә.

Әйе, һәр кешенең “менә ул чын укытучы” диярлек остазы бар. Ул аны еллар үткән саен сагынып искә ала, гомер буе аңа рәхмәтләрен укый. Минем дә андый кешем бар.Ул минемтатар теле укытучым, сыйныф җитәкчем - Иркәнур апа Вәгыйзова. Аның яхшы сыйфатлары: тыйнаклыгы, кешелеклелеге, кешеләргә ярдәм кулы суза белүе -һәммәбезгә һәрвакыт үрнәк булды. Безнең күңелләребезгә изгелек орлыкларын чәчте, бөтен тормыш тәҗрибәсен, белемен безгә бирде, күңел җылысын өләште. Ул чәчкән игелек, шәфкатьлелек орлыклары да тигез шытымнар бирде, үсте,ә аларны корытмау, саклап калу инде безнең кулларга күчте. Укытучы апамның әдәбияттанбиргән белеме, кызыксындыра белүе, тырышлыгы миңа һөнәр сайлауга зур этәргеч булды.

Олы яшьтә булуына карамастан, остазым әле һаман да миңа үзенең киңәшләрен бирә, уңышларымны күзәтеп бара, минем өченяшь баладай сөенә. Мин аңа мең-мең рәхмәтлемен.

Тормышны диңгезгә охшатам мин. Ә мин – шул иксез-чиксез диңгезнең кечкенәгенә инешчеге. Менә әле кайчан гына мин дә, нәни генә инеш булып, шул зур тормыш диңгезенәкилеп кушылган идем. Яшәү көче, тормыш дәрте белән ярсыган яшь йөрәгем, ташларны актарып, каты ярларны кисеп, һаман алга омтылды.Остазым күрсәткән юлдан тайпылыйча баруым да нәтиҗәсез үтмәде. Сәләтле укучыларым шәһәр, республика күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда, бәйгеләрдә лаеклы урыннарда баралар. Ышанычлы адымнар белән әле тагы да алга барырга кирәклеген күңелем белән сизәм.Бүгенге көндә мин үземне бик бәхетле дип саныйм: яраткан эшем, ярдәмчел хезмәттәшләрем, мине хөрмәт итүче укучыларымбулу, миңа юл күрсәткән остазымның исән-сау булуы – ул үзе зур бәхет. Димәк, укытучы булыпялгышмаганмын.

Хезмәт көнем тәмамлангач, көн дә бер үк сукмактанашкынып яраткан гаиләмә кайту,ә анда мине иң якыннарым көтеп тору – бу бәхет түгелме?!

Бәхетле чак – әзме, сизмибезме?
Ник белмибез бәхет икәнен.
Бәхет булмый,ниләр булсын инде
Кайгыларның үтеп киткәне?
Күрәлгәнгә шушы дөньяларны,
Күкрәк тутырып һава алганга.
Бәхетле мин, җан җылысы бирер
Җангаякын *телем*булганга!!!

**Түбән Кама шәһәре 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы**
**Әхмәтгалиева Зәлифә Габрахман кызы**

Минем укытучы һөнәрен сайлавыма остазым Зәлифә апа зур этәргеч булды. Бер мин генә дә түгел.Югыйсә,унбиш укучының сигезе укытучы һөнәрен сайламас иде.

Тирә-як авылллардаЗәлифә апаны белмәүчеләрбик сирәк. Зәлифә апаның бала чагысугыштан соңгы елларга туры килгән. Ятимлектә үскәнгәме, тормышның ачысын-төчесен күп татыган ул. Тумышы белән Актаныш районы Усы авылыннан.

Ире Габдулла абый белән өч кыз үстерделәр.Хәзер инде алар тормышта.

Чын укытучы нинди булырга тиеш дисәләр, бу безнең Зәлифә апа дияр идем. Ул үз фәнен яхшы белүче укытучы гына түгел, тирән фикерләүче әңгәмәдәш тә, төпле киңәшче дә, акыллы, җитди,шул ук вакытта бик гади дә була белә иде. Шушы сыйфатлары белән ул үзенә тартып тора. Аның сүзен кайчак үтисе килмәсә дә, курыкканга түгел, ә хөрмәт иткәнгә башкара идек.

Без, дүрт кыз, Качкын авылына 6-7 км. йөреп укыдык.Чит авылда булуга карамастан, ул безнең өйләргә килеп китәргә дә авырсынмый иде. Сыйныф сәгатендә Габдулла абый малайлар белән әңгәмә корса, без Зәлифә апаның өендә тәмле тәбикмәк белән сыйланып төпле киңәшләр ала идек.

Хәтеремдә, унынчы сыйныфта укыганда Зәлифә апа безгә Мостай Кәримнең “Айгөл иле”спектаклен куярга тәкъдим итте.Сәгатьтән артыкбарган әсәрне халык бик яратып карады. Ә безнең өчен күпме истәлек, якты хәтирә калды.

Бик тыйнак кеше булгангамы, ул вакыттабез аның шигырьләр язуын белми дә идек.Соңгы кыңгырау бәйрәмендә махсус безнеңөчен язганшигыре таң калдырды.Район газетасында бүгенге көндә аның тирән эчтәлекле, гыйбрәтле мәкаләләре басылып чыга.

Күңелемдә калган тагын бер истәлекле вакыйганы әйтеп китмичә булдыра алмыйм.Зәлифә апаЯңа ел бәйрәменәбезгәкитап бүләк итте . Ул китапларда һәрберебезгә багышланган шигырь юллары язылган.Хәсән Туфанның шигырьләр китабы иде ул :

Мин баш иеп озатып калам,
Башым иеп киләчәкякка.
Безне дәвам итәчәк сафка, диелгән.

Бу сүзләрнең мәгънәсен ул вакытта бәлки аңлап та бетермәгәнмендер.Укытучы булырмын, дигән уй башыма да кереп карамый иде бит. Менә шушы сүзләр, бәлкем, миңа канат куйгандыр. Бәлкем, аның алдан күрү сәләте дә булгандыр. Сүзләр чынга ашты. Үзем дә шушы һөнәрнесайладым.

Зәлифә апаның тормыш юлымда очравы белән мин бик бәхетле. Шул ук вакытта, аның укучысы булуҗаваплылык та өсти. Егерме ел укыту дәверендә төрле хәлләр булгандыр. Мин үз-үземә һәрвакыт: “Зәлифә апамондый очракта нишләр иде микән ”,-дип сорау бирәм. Хәер, ул чорның балалары да башка булгандыр, мөгаен.Ни генә булмасын һәр чорның үз остазлары була. Минемчә, чын укытучы иң беренче чиратта Зәлифә апа кебек кешелекле булырга тиештер.

Без, аның укучылары, аны беркайчан да онытмыйбыз. Балаларның тормышында калдырган якты эзул беркайчан да югалмый.

**Түбән Кама шәһәре 29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы**
**Корычбаева Гузель Салимовна**

“Уңышсызлыклардан курыкмаган
кеше генә зур уңышка ирешә ала”.
Роберт Кеннеди

Остаз…оста, өйрәтүче, укытучы.

Кечкенә вакытта, без барыбыз да нинди генә һөнәр ияләре булу турында хыялланмыйбыз.Сюжетлы уеннар уйнаганда кемнәр генә булмыйбыз:космонавт, сатучы, артист, укытучы, табип һәм башкалар.

Үсә төшкәч хыяллар үзгәрә.Тормышта барлык һөнәрләрне дә өйрәнеп бетереп булмаслыгын аңлыйсың.Үзеңә башка максатлар куя башлыйсың.

Кеше бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсә дә, аның уңышлары башында укытучы тора.Атаклы педагогК. Д. Ушинский да: “Укытучы һәрдаим укыганда гына

укытучы булып кала", – дигән. Әйе, тырышмыйча гына укучыларга үз фәнеңне яраттырып булмый. Үзалдыңа билгеле бер максат-бурычлар куеп, шуларны тормышка ашырганда гына моңа ирешергә була.

Мин дә,бакча яшеннән чыгуга, укытучы булырга хыяллана идем. Монысәбәбе дә бар-улберенче укытучыбызМәккә апа.

Безаңа бөтен сыйныфыбыз белән гашыйк идек. Уляңа укып бетереп, безнең мәктәпкә эшкә килгән,яшь, чибәр кыз .Аның барлык сорауларга да җавап таба белүе,уңганлыгы, җитезлегебезне һәрчак сокландыра иде.Без һәрчак аңа охшарга тырыштык.

Мәктәпне тәмамлаганга да егерме еллап вакыт узды. Ә тормыш юлларым мәктәптән барыбер аерылмады. Хәзер инде үзем укытучы. Һәр иртәне дәрескә ашыкканда да, сыйныф ишеген ачып кергән вакытта да,балаларның җавап көтеп текәлгән сораулы күз карашларын күргәндә дә ирексездән бала чагым күз алдыма килеп баса.

Мәккә апа минем укытучым гына түгел, ул минем остазым да. Чөнки һөнәр сайлаудамиңааның йогынтысы зур булды.Югары уку йортында укыганда да,мәктәптә эшли башлагач та үзенең киңәшләре белән һәрчак ярдәм итепторучы Мәккә апабыз хәзер лаеклы ялда.

Ләкин укытучы-остаз һаман укытучы булып кала инде ул,
Кайчан гына барсаң да кире бормый, кирәкле сүзләрен таба, аңлата, киңәшен бирә.

Укытучым даСез,остазымда
Маяк кебек тормыш юлында.
Рәхмәт әйтеп Сезгә башым иям
Чәчәк бәйләмнәре кулымда!

**Түбән Кама шәһәре 29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы**
**Әхмәтшина Мәрьям Вәлиахметовна**

Бүген мин сезгә остазым, сыйныфымның җитәкчесе, мөгаллимем Дания Мирза кызы турында сөйлисем килә. Әйе, нәкъ менә мөгаллимем, мөгаллимәмдип әйтәсем килә. Ни өчендер, бу сүз, укытучы сүзе белән чагыштырганда, тирәнрәк мәгънәгә ия сыман.

5 нче сыйныфтан башлап, мәктәпне тәмамлаганга кадәр, безнең белән янәшә булды Дания апа. (Без аңа шулай дәшә идек). Хәзер авыл мәктәпләрендә сыйныф саен биш, алты, җиде бала. Ә без сыйныфта 36 идек: 36 бала, 36 төрле холык. Уйлыйм да- гаҗәпкә калам: ничек шулай барыбызны да күрә, ишетә, аңлый белде икән ул?Үзе бездә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барды. Бик мавыктыргыч итеп сөйли белә иде Дания апа. Без аны, ачкан авызыбызны да йомарга онытып, йотлыгып тыңлый идек. Ул безне туган телебезне яратырга, хөрмәт итәргә өйрәтте. Кыскасы, үз эшенең остазы иде Дания апа. Нәрсә генә әйтсәм дә, аны ничек кенә мактасам да аз кебек. Шуңа күрә бөтен хисләремне, әйтер сүзләремнешигырь юллары белән әйтеп бирергә теләдем. Менә шундый шигырь туды. Рәхим итеп тыңлагыз.

Мөгаллимем.
Язучы да үзең, артист, оратор да,
Биюче дә, тагын әллә кем...
Нинди генә талант юк бит синдә,
Ләкин гади бит син, мөгаллим.

Рәхмәт сиңа ныклы белем биргән өчен,
Рәхмәт сиңа ярдәм кулың сузган өчен,
Рәхмәт сиңа безне якын иткән өчен,
Рәхмәт сиңа барысы-барысы өчен.

Үз баладай якын күрәсең син
Каршыңдагы һәрбер сабыйны.
Үрнәк табигатең, акыллы киңәшең
Якынайта безнең араны.

Рәхмәт сиңа ныклы белем биргән өчен,
Рәхмәт сиңа ярдәм кулың сузган өчен,
Рәхмәт сиңа безне якын иткән өчен,
Рәхмәт сиңа барысы-барысы өчен.

Үтсәләр дә еллар, күз алдымнан китми,
Мөгаллимем, якты йөзләрең.
Һәрчак яшь булып кал, озак яшә,
Җитмәсеннәр тормыш көзләрең.

Рәхмәт сиңа ныклы белем биргән өчен,
Рәхмәт сиңа ярдәм кулың сузган өчен,
Рәхмәт сиңа безне якын иткән өчен,
Рәхмәт сиңа барысы-барысы өчен.

**К.С. Байкиев исемендәге кадетлар интенат-мәктәбе укытучысы**
**Гарәфиева Миләүшә Ибрагимовна**

«Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч я сабырлык,
Сиздермичә ярдәм иткәнсез -
Сез иң күркәм кеше икәнсез”

Укытучы! Остаз! Мөгаллим! Бу сүзләргә күпме мәгънә салынган. Һәр кеше аңа үз төсмерен сала, үз буяуларына буйый. Безгә бик еш кына тормышта “укытучысы яхшы булгандыр” дигән сүзләрне ишетергә туры килә, чөнки бала тормышында укытучының роле чиксез зур. Баласына битараф булмаган ата-ана, дөрестән дә, баласы өчен белемле, акыллы, тәҗрибәле, үз эшенә бирелгән остаз эзли. Бары тик үз үрнәгендә һәм үзеңне үрнәк итеп күрсәтеп кенә балага дөрес тәрбия биреп була. Бала үз укытучысына охшарга тырыша, аның кебек атлап йөри, аның кебек көлә, аныңча фикер йөртергә тырыша. Остазының сүзе, фикере – иң дөресе, иң акыллысы.

Укытучы! Ул – һәр һөнәргә юл башы. Бөек акыл ияләре дә, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән каһарманнар да, ачышлары белән танылган галимнәр дә, әдәбият, сәнгать, мәдәният әһелләре дә, ил башлыклары да ирешкән уңышлары өчен, беренче чиратта, үз укытучыларына, остазларына бурычлы.

Һәр укучының яраткан фәне һәм яраткан укытучысы була. Минем дә бар андый кешем, ул – Сафина Энисә. Мин аны укытучым дип кенә түгел, ә остазым дип тә атар идем. Энисә апа Сафина күп еллар Саба районы Тимершык урта мәктәбендә башлангыч сыйныфларга белем бирде. Минем үземнең педагог булып китүемдә аның роле бик зур. Аның яхшы сыйфатлары: тыйнаклыгы, кешелеклелеге, кешеләргә ярдәм кулы суза белүе һәммәбезгә һәрвакыт үрнәк булды. Шулай ук, ул оста педагог, психолог та була белде. Укытучымнын биргән белеме, кызыксындыра белүе, тырышлыгы миңа хонэр сайлауга зур этәргеч булды. Аңа охшарга тырышып, мин филология булеген сайладым, татартеле һәм әдәбияты укытучысы булып киттем.

Бугенгесе кондә мөгаллимәм лаеклы ялда. Ул узен яраткан гаиләсенә, балаларына багышлады. Дин юлыннан китеп, абыстай буларак халыкка хезмәт курсәтә. Әлеге һөнәрне сайлавыма мин үкенмим. Үз һөнәремне яратып башкарам. Менә инде 18 ел мин укучыларга татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирәм. Төрле конкурсларда катнашам. Укучыларым да бик теләп катнашалар, призлы урыннарга ия булалар. Район һәм республика олимпиадаларында җиңү яулыйлар.

Укытучы булу җиңел түгел! Укытучы һөнәре - чын мәгънәсендә һөнәрләр һөнәре. Мөгаллим ул - гомере буе укый, өйрәнә, үзенең һәм укучыларының уңышларына чын күңелдән сөенә белүче, көчле ихтыярлы, сабыр кеше. Балаларны яратучы, хөрмәт итүче, барачак юлларында маяк булып торучы изге зат. Башкача мөмкин дә түгел, минемчә, чөнки ул ШӘХЕС тәрбияли. Укытучының үз "чәчү вакыты", үз "урак өсте" бар. Аларның сабырлыгы аналар сабырлыгына тиң, юкка гына укытучыларны әниләргә тиңләмиләрдер.

Мин үземнең яхшы укытучы булуыма ышанам! Бала күңеленә изгелек орлыклары чәчкәндә, бөтен тормыш тәҗрибәмне, белememне балаларга бирәм, күңел җылымны өләшәм. Мин чәчкән игелек, шәфкатьлелек орлыклары да тигез шытымнар бирә, үсә, тик алар корымасыннар гына иде. Аларны саклап калу - минем изге бурычым. Һәр баланың күңел түрендә чын мәгънәсендә УКЫТУЧЫ булып калсам иде.

"Җир йөзендә иң-иң матур теләкләрне,
Сорасалар багышларга кемгә, диеп.
Үзенә бик күп йөрәкләрне әсир иткән,
Укытучыга, дияр идем, башны иеп."(Лена Шагыйрьҗан.)

Укучыларым минем юлымнан китсәләр, бик соенәм. Беренче укытучымны да онытып бетермим: даими рәвештә хәлен белешеп тора. Өлкән кешегә куп кирәкми. Безнеңүз остазларыбызны онытырга хакыбыз юк.

**Түбән Кама шәһәре**
**11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы Вагизов Фәрит Яхъяевич**

***"Минем шәхси остазларым..."***

*Кемне генә сокландырмас*
*Укытучыныңхезмәт җимеше.*
*Балаларга гыйлем бүләк итә*
*Нинди бөек хезмәт аның эше!*

Безнең "XX нче гасыр мәктәбе"музеенда бик кызыклы экспонатлар күп: агач саплы каләмнәр, пыяла кара савытлары, ярты гасыр элек басылган әлифба китаплары... Тикдистәләгән уку-язу әсбаплары, укытучыларның шәхси әйберләре һәм башкатарихның телсезшаһитлары арасында минем күңелемә иң якын бер әйбер бар. Ул – "РСФСР халык мәгарифе отличнигы" дип аталган күкрәк билгесе. Бу45 еллык педагог стажыбулган, "Бөек Ватан сугышы елларында фидакарь хезмәте өчен" һәм башка күп медальләр бүләкләнгән әтием Яхъя Вәгыйзулы ядкаре.

Элек мәктәпләрдә пөхтә язу дәресләре бар иде. Мин матур язарга әтиемнең дәфтәрләрен карап өйрәндем. Үземне күпме хәтерлим, әтиемнең кул язуы гаҗәп матур иде. Ә бит каллиграфия кешенең түземлек, тырышлык һәм үҗәтлеге турында күпне белдерә. Инглиз телендә "the man who made himself" - "Үзен Кеше иткән кеше" дигән әйтем бар. Әтием Яхъя язмышы бу сүзләргә бик туры килә. Ачы сугыш еллары һәм сугыштан соңавыр чорларга карамастан, ул үз алдына куйган максатына ирешкән. Минемчә, төп сәбәбебабасының васыятен намуслы үтәргә омтылыш булгандыр. Әти безнең Мөслим ягыннан, Ык буендагыТүбән Табын авылыннан. Аларның нәселендә, бабасының бабасы Гәбделвахитмулла булган.Аның улы Маликмуллаәч мәхәллә тоткан, мәдрәсәдә укыткан. Үзенең улы Вәгыйзга, ягъни минем бабайгакатгый рәвештә белем алырга, укымышлы

булырга васыять әйткән. Кызганычка каршы, бабайның ул теләге тормышка ашмаган. Канлы октябрь инкыйлабытегермәне ташлары бөтен уй-планнарны челпәрәмә китереп-уалтып ташлый. Кулак итеп Мәлик бабайны Себергә сөрәләр, 5-6 елдан соң бик авырып әйләнеп кайта. Аксап йөри, сөргендә аяк табаннарын такта белән сугып эштән чыгарганнар була. Атасы мәрхүм булгач, Вәгыйзяшьтән колхоз тәртәсенә җигелә. Ә аннары ул Бөек Ватан сугышы кырларында хәбәрсез югала...

Биш бала арасындаөлкән улЯхъягаиләдә баш булып кала. Ярый әле Ык буеның болын-тугайлары үзләренең бар җимешләре белән ачлык авырлыкларын кичеп чыгарга ярдәм итәләр. Кемнеңдер киңәше буенча, эти өйянындагы бакчада тәмәке үстерә башлый, көз көне аны базарда сатып йөри... Сугыш беткәч, 1946 нчы елны этиМинзәлә педагогия училищесына укырга керә. Тырышып укыргаачлык, кием-салым юклык та комачау итә алмый. 1950 нче елныэти диплом белән Актаныш районына, Яңа Әлем балалар йортына эшкә җибәрелә. Ә аннары 5 ел буе Совет Армиясе сафларында авиацияполкында механик ярдәмчесе, дивизия штабында писарьбулып хезмәт итә. 56 нчы елның иртә язында, урсып-ярсып ага башлаганАгыйделне көч-хәл кичеп, тагы Актанышка кайта.Ашкынуы юкка булмый, чөнкиЯңа Әлемдә аны 5 ел элек вәгъдә биреп озаткансөйгәне Мәхмүзә, минем булачак әнием өзелеп көтеп тора...Алар кавышып озакта вакыт узмый, балалар йортын икенче авылга – Такталачыкка күчерәләр.Шул вакытта этине башта укыту эшләре буенча урынбасар, ә аннары инде директор итеп билгелиләр.

Хәзерге көнкүзлегеннәнкараганда,этиемнең педагогик осталык серләре бик гади иде. Аны мәктәп укучылары бик яраттылар. Чөнки аның дәресләре бик кызыклы, җанлы була . Яңа тема аңлатканда, ул һәрчак аны тормышчан һәм практик кулланышка бәйләп алып бара. Зур тормыш тәҗрибәсе аңа хәтереннән кирәкле мисаллар табып, аларны дәрестәге төрле ситуациягә бәйле рәвештәаңлатырга ярдәм итә иде. Ул беркайчанда үзенең белем дәрәҗәсен үстерү өстендә эшләүне туктатмады. Бик еш Казанга курсларга бара иде, кире кайтканда кочак-кочак китаплар төяп кайта. Авылда без газета-журналларны иң күп алдыручы булганбыздыр... Ул чакта щәһәр китапханәләрендә таба алмаслык “дефицит” басмаларны ала идек. Мәсәлән, “Роман-газета” журналын.Узган атнада 100-еллык юбилее узганАлександр Солженицынның“Иван Васильевичның бер көне” әсәрен 6 нчы сыйныфта укып чыкканым истә калган.

Әтиемнең нинди педагогик кулланмалары хәтеремә сеңеп калган соң? Детдомнан тыш улурта мәктәптә рус телеукыта иде. Бер елны безнең сыйныфта сызым дәресләре алып барды. Ул вакытта альбомбитенә төрле чертеж-эскизлар ясарга өйрәндек. Әти безне гади рәсемнәрдән катлаулырак сызымнар ясарга өйрәтте. Мәсәлән,чүкеч сабы сызымы. Мин элек уйлый идем,сап ясауның нинди авырлыгы бар инде аның, бер таяк юынасың да куясың... Юк шул, ул аз булса да конус рәвешендә булырга тиеш икән. Әти сыйныфка (хәзер инде проблемалы укыту методы дип әйтерләр иде) сораулар куйды – ни өчен конус булу кирәк? Кайсы башка юнәлтелгән булырга тиеш? Нинди материаллар кулланырга кирәк һ.б.? Шунысын ассызыклапузарга кирәк, эти бар эштә дә үзе үрнәк күрсәтте. Шул ук сызымнарның астындагы язуларны басма хәрефләр белән бернинди әзерлексез тип-тигез яза иде, ә без линейкалар белән астан-өстән сызып та, дәрес буе мәш килә идек...

Элек сыйныф журналларында кайбер укытучыларконтроль эштән соңграфа буе “икеле”ләр тезеп чыгалар иде. Миннән өлкәнрәк сыйныф укучыларыннан ишетә идем:

- Вагыйзов “икеле” түгел, нокталар гына куя. Тик 3 нокта булса, көн саенөстәмә дәрескә калдырып, күрмәгәнеңне күрсәтә.Ә аның “өчле”се “бишле”гә тиң икән...

Бу сүзләрнең дөреслеген ул укытып чыгарган бик күп балаларның югары уку йортларына керүе, аннары яхшы белгечләр һәм җитәкчеләр булуы раслый. Мәсәлән, Фасыйл Касыймов мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Казан университетының физика-математика факультетына укырга керде. Аннары үзе дә мәктәпкә эшкә кайтып, югары квалификацияле укытучы дәрәҗәсенә иреште. Әтинең танылган укучылары арасында фән кандидатлары,директорлар, хәрби офицерлар, төрле җитәкчеләр күп булды.

Әтиемнең уңышлары турында сөйләгәндә, әнием Мәхмүзәнеһич тәискә алмыйярамый.Әнием кечеяшьтән әтисез калган, ә әнисе Ленинград блокадасыннан чыккач вафат була. Әниемнең педагогик белем алырга мөмкинчелеге булмый, ләкин ул да шулай ук бар тормышын мәктәп,балалар йорты һәм интернат белән бәйләгән. Балалар аны ничек нык яраттылар! Ул үзе бик ягымлы һәм җылы күңелле кеше иде. Әмма тәртип, чисталык һәм пөхтәлеккә бик таләпчән булды.Мәсәлән, утын әрдәнәсен өясең икән,ул Кремль стенасы кебек төп-төз булсын; түтәл казыйсың икән, туп-туры почмаклы булырга тиеш!Пионервожатый яки тәрбияче булып эшләсә дә, төннәр утырып эш планнары яза иде. Мәктәптә укытучылар җитмәгәндә хезмәт, җыр һәм рәсем дәресләрен алып барды. Үзешчән сәнгать концертлары оештырырга ярата иде. Аның балаларда әз генә булса да иҗади очкын күреп, шуны кабызып җибәрергә, аларның талантларын ачу осталыгы бар иде.Күпме биючеләр,нәфис сүз осталары әзерләгәндер ул! Күпме ятим балалар белән ул үзенең кайнар йөрәк җылысын уртаклашкандыр...Мәктәптән соң,уку вакытында “авыр үсмерләр”дипйөртелүче балалартормышта үз урыннарын тапкач,өйләнгән яки кияүгә чыккан вакыттаминем әти-әниләрне никах,үз балалары тугач бәби туйларына чакыралар иде.Алардан: “Әгәр дә сез булмасагыз, Яхъяабыйһәм Мәһмүзә апа,без беркайчанда мәктәпне тәмамлый алмас идек...” дигән сүзләрне бик еш ишетә идек.

Мәктәптә генә түгел, үз балаларында даәтиемһәрчак белемгә һәм китапка мәхәббәт уятырга омтылды. Үзе шигърияткә бик ярата иде – Тукай, Такташны.. . Шул ук вакытта рус шагыйрьләре иҗатын да яхшы белде. Бер вакыт, кыш башында, яңа яуган кар өстеннән атлы чана белән без печән алып кайтырга Каракай чокыры дип аталган басу ягына киттек. Гаҗәеп матур кояшлы көн иде, ат чаба, чана шыгырдый... Шул вакытта әтием кычкырып шигырь укыйбашлады:

Зима, крестьянин торжествуя,  
На дровнях обновляет путь,  
Его лошадка, снег почуя  
Плетется рысью, как-нибудь...

Пушкинның иҗатына мәхәббәтем шулай башланды.Икенче бер вакыт әти шулай Лермонтовның шигъриюллары белән таныштырды...Бәлкем шул сәбәпледер инде, үзем 7-8 сыйныфларда укыганда бераз каләм тибрәтә башлагач, урта мәктәпне тәмамлап Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагыжурналистика бүлегенә укырга кердем. Уку йортын тәмамлагач, ике дистә елдан артык газеталарда, телевидениедә эшләдем. Үзгәртеп кору еллары башлангач, “Шин” берләшмәсендә татарча газета ачуны гамәлгә салдым, татар теле укыту курсларында укыттым. 16 нчы мәктәпнең элеккеге директоры Т. Әхәтов бик үтенеп сорагач төп эшемнән ( газета мөһәрире) тыш, татар теле дәресләрен факультативсәгатьләрдә укытып йөрдем. 2011 нче елдан Татарстан кадетлар корпусында эшләдем, хәзер инде бишенче ел 11-нче мәктәптә татар теле һәм әдәбият дәресләрен алып барам.

Әти-әниләребезнеңтәрбия җимешләребезгә үзебезнеңкиләчәк тормышыбызда нык ярдәм итте. Дүртебез укытучы һөнәрен сайлады. Бүген сеңлем Фәйрүзә Яхъя кызы Манихова педагогик фәннәр кандидаты, Түбән Кама педагогика колледжыдиректоры. Икенче сеңлем Рәмилә Татарстан Президентының мәгариф өлкәсендәге Грантка лаек булган югары категорияле укытучы. Төпчек сеңлебез Райлә шулай ук педагог һөнәрен сайлаган иде, кызганычка каршы,фаҗигале рәвештә вафат булды.Башкатуганнар арасында да укытучыларбик күп. Мәсәлән, Түбән Каманың 2 нче урта мәктәбендә директор урынбасары булып эшләүче РозаГәйсәр кызы Сәгъдиева, Иске Чүпрәле интернат-лицеендадиректор һәм укытучыирле-хатынлы Баһаутдиновлар, Алабугада 8-нче мәктәптә эшләүче Ләйсәнә Сәгъдиева һәм башкалар. Безнең педагогик династиянең гомуми стажыинде 250 елданартып китте!

Укытучы. Бу сүздә күпме мәгънә ята. Кем генә зур ихтирам белән телгә алмый икән бу исемне. Мәктәптә белем бирүче, аерым бер фән алып баручы, фикер йөртүче, җәмәгатьэшлеклесе, тормыштабалаларга үз юлларынтабарга булышучы һәм алардан дөньяга

караш,ышанулар тәрбияләүче,үзенең яшәү тәҗрибәсе белән аерым шәхес тәрбияләүдә тирән эзләр калдыручы, бала күңеленә иң якын кеше ул.Мәктәпне тәмамлап, тормыш юлына атлаганда,мин бу һөнәр иясенең нинди кеше булуы турында тулысынчааңлап бетермәгәнмендер. Әти-әниемнең һөнәрен дәвам итүне мин башта максат итеп куймадым.Ә менә укытучы һөнәренең нинди катлаулы, җаваплы һөнәр булуын минеллар узгач гынатулысынча аңладым. Әти-әниемне олугъ остаз дип аларныңһәрчак балаларда шәхес күрә белүләрен, аларга ихтирам белән карау таләбентайпылмыйча үтәүләре өчен хөрмәтем гаять зур. Алар мине мәктәпне һәм балаларны яратырга өйрәттеләр. "Мәктәп юлы – җәннәт юлы", - дип юкка гына әйтмиләр бит.

Бүген укытучы алдына куелган бурычлар бик зур. Укытучы эшен бакчачы хезмәте белән чагыштырырга мөмкин: педагог балаларга белем һәм уңай тәрбия орлыкларын "чәчә". Ул орлыклар яхшы җимеш бирмичә калмыйлар. Чөнки алар иң уңдырышлы җирдә – балалар күңелендә үсәләр.Мәгърифәт белән күпме сокландыргыч шәхесләрнең искиткеч язмышлары бәйләнгән. Тик мин иң беренче чиратта үземнең укытучы әти-әниемнәр алдында баш иям. Алар минем иңакыллы, иң гүзәл, иң күркәм остазларым иде һәм күңелем түрендә алар турында якты истәлек һәрчак сакланачак!

**Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбият укытучысы**
**Нуриева Ләйсән Зәкәриевна**

*"Минем остазым" (Мөхәммәт Мәһдиев истәлегенә)*

Безнең курс Яр Чаллы Дәүләт педагогия институтында татар филологиясе факультеты оешып, аның гөрләп эшләү дәверенә туры килде. Кураторыбыз шагыйрәРәзинә апа Мөхиярова, укытучыларыбыз Әнвәр Мәгъданурович Шәрипов, Рәвия Саматовна Абдуллина кебек күренекле галимнәр иделәр. Без Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллин, Мөхәммәт Мәһдиев кебек бөек шәхесләрнең курсларын тыңлаган буын.Әлеге мөгаллимнәрнең барысы да зур хөрмәткә лаеклар.

Бүген минем мәшһүр татар язучысы, әдәби тәнкыйтьче, әдәбият галиме, укытучыМ.Мәһдиев турында сөйлисем килә. Ул миндә әдәбият укытуга аерым караш тудырган шәхес. Без укыган чорда Мөхәммәт абый кебек институтныңтатар бүлеге студентлары симпатиясен казанган укытучы тагын булдымы икән?! 18—20 яшьлек егетләр—кызлар анарга мөкиббән идек. Чөнки ул Тукай әйтмешли, "коеп куйган" укытучы гына түгел, ә артист та, философ та, психолог та иде. Аның дистәләгән шәкертләре хәзер республикабызда һәм башка өлкәләрдә бик тырышып мәгърифәт нуры тараталар.

Дуртенче курста укыган вакытта безгә әдәбият фәненнән өстәмә дәресләр куйдылар. Казаннан М.Мәһдиев үзе килде! Икенче көнгә аудитория ике группа студентлары белән шыплап тулган иде. Бүгенгедәй хәтеремдә: ул басып сөйләгән трибуна тәрәзә янына урнашкан. Куллары белән трибуна читенә тотынып,башын гел бераз тәрәзәгә бора төшеп сөйләде ул. Кемдер, хәтерем ялгышмаса, Марсель Галиев бугай, язып та чыкты әле. "Мәһдиев, сөйләшкәндә, әңгәмәдәшенә ян белән торуны кулай күрә, чөнки безнең татар сүзен тыныч кына әйтә алмый, корсакка, күкрәккә төртә башлый, дип әйткән ди", имеш. Бу сүзләр хактырмы, юктырмы? Ләкин менә Мөхәммәт аганың тавышының матурлыгы күпләребезне әсир итте, төркемдәге барлык кыз-егетләрне авызына каратып тота алды ул.

Мөхәммәт Мәһдиевнең прозада беркемне дә кабатламый торган үз стиле, үз язу манерасы булган кебек, лекцияләре дә бик үзенчәлекле узды.Конспектязып бару мөмкин түгел, шулкадәр тәэсирле сөйли - кәгазь-каләм кыштырдатып, бу илаһи мизгелне бозарга

берәү дә җөрьәт итми. Ләкин шулай да әтисенең тәрбия өлкәсендәге 3 таләбен язуны сорады ул бездән.

- Ялганлама. Тик дөресен генә сөйлә.
- Урлама. Кеше малына, дәүләт милкенә кагылма.
- Укытучы алдында белгәнеңне яшермә. Бераз белсәң, кул күтәр. Укытучы үзе сиңа ярдәм итәр. Нинди акыллы һәм төпле сүзләр.

"Аяклы энциклопедия", күп белүче, тормышның төрле өлкәләрендә барган яңалыклардан хәбәрдар, рус һәм читиләдәбиятын күп укыган, гомумән, кеше психологиясен яхшы тоемлаучы укытучы булып калды ул безнең хәтердә. Аның курслары төгәл бер атна дәвам итте, шул дәвердә ник бер кәгазь тотып керсен дә,ник бер язудан карап сөйләсен... Тагын шунысы истә калган: авылдан чыкканыгызны беркайчан да яшермәгез һәм оялмагыз диде ул безгә.Татар авылларына дан җырлаган язучының сүзләренә ничек колак салмыйсың инде?!

Иң кызыгы зачет вакытында булды. Шимбә булганлыктан, (барыбызга да авылга кайтырга кирәк) мине иң беренче кертеп җибәрделәр. Каршыда Мөхәммәт Мәһдиев үзе! Дәфтәрдә тотып сөйләрлек әллә нәрсә дә язылмаган. Каршысына килеп утыргач: "Я сеңлем, сезнең авылдан нинди күренекле шәхесләр чыккан?"-диде. Ике дә уйлап тормыйча: "Рөстәм Маликов, - мин әйтәм. –Ул безнең күршедә әле,"- дип киттемҗырчы турында сөйләп. И яратып тыңлады мине укытучым. Азакта: "Роман Солнцев та сезнең якныкы, аның турында да белеш әле, зачет сиңа",- дип чыгарып җибәрде.

Төркем белән иң үкенгәнебезшул: ул атнадатулай торактагы фотограф Салаватны таба алмадык. Ичмасам, автограф та алып калмаганбыз бит. Әй яшьлек, яшьлек. Укытучыбыз яшьлекнең кадерен белегез, сезнең иң рәхәт чагыгыз, сез сугышны күрмәдегез дип, үзенең яшьлек елларыннан бик күп истәлекләр дә сөйләде. Мөхәммәт абый безнең киләчәгебезне матур итеп күрергә теләде. Педагогика өлкәсендә безгә бик күп киңәшләр бирде, мин аннан бик күп әйбергә өйрәндем:

1. Теманы дәреслеккәкарап аңлатмаска.
2. Дәрестә салмак тавыш белән сөйләргә.
3. Авыл баласы булуыңнан оялмаска.
4. Әдәбиятнытормыш белән бәйләп алып өйрәтергә.

Мөхәммәт Мәһдиев тормыш авырлыкларын бик күп кичерсә дә, күңел матурлыгын, юмор хисен югалтмаган укытучы иде. Улгаfive тирән дәрәҗәдә кеше күңеленең нечкәлекләрен аңлый, күрә һәм шуны безгәҗиткерә белде. Аның дәресләрендә мин кешеләрне чиксез яратырга, үз итәргә, һәр кешенең кызыклы сыйфатларын күрә белергә өйрәндем. Безнең күңелләргә матурлык сала белгән укытучы ул- Мөхәммәт Мәһдиев!

**Минзәлә районы Кадрәк авылының гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы**
**Евграпова Зөлфия Зәкиевна**

Бу тормышта минем адымым нык,
Укытучы – минем һөнәрем.
Бар көчемне, талантымны биреп,

Балалар, дип уза көннәрем.

Укытучы! Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән телгә алмый икән? Һәркайсыбызның иң матур хәтирәләре, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйле. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, бала белән янәшәдә аның укытучысы атлый. Бүген галим дә, ташчы да, иген үстерүче дә аның олы исеме алдында баш ия, чөнки теләсә нинди һөнәргә юл башы укытучының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә салына. Ул дөньядагы барлык матур сыйфатларны үзенә туплаган. Киң күңеллелек, тырышлык, балаларга чиксез мәхәббәт, намуслылык… Уйлап карасаң, укытучы булу җиңел түгел! Минем уйлавымча, чын мөгаллим булыр өчен гомер буе укырга, өйрәнергә, иң мөһиме балаларны яратырга һәм хөрмәт итә белергә кирәктер, мөгаен.

Бүгенге көн укытучысы белем чыганагы гына булып калмыйча, галим дә, күпләр өчен идеал, үрнәк тә булырга тиеш. Минем өчен шундый мөгаллим булып, башлангыч сыйныфлар укытучысы –Баева Сәйдел апа торды. Ул бик төгәл, таләпчән, мәрхәмәтле иде.Аның нәни кулларымнан тотып беренче хәрефне язарга өйрәтүе,санау таякчыклары тотып санарга өйрәтүе,бер рус сүзе дә белмәгән балаларны русча шигырьләрятлатуы әле дә хәтеремдә.

Безнең уңышларыбызга әниләребез сыман сөенүе,бигрәк матур язгансың дип аркалардан сөюе бүгенгедәй күз алдымда.Минем кечкенәдән үк Сәйдел апа сыман балаларны нәни кулларыннан тоттырып язарга,санаргаөйрәтәсем килде.Алар белән бергә уйныйсым,йөгерәсем,сикерәсем килде.Һәм мин кечкенәдән уйланган хыялымны тормышка ашырдым.Мин нәни балаларны бик яраттым,хәзер дә яратам.

Әйе, мин бәхетле. Авыр, җаваплы булуына карамастан, бу һөнәрне сайлавыма һич үкенмимен. Гомеремне бушка уздырмавым өчен сөенеп туя алмыйм. Үзең яраткан эштә узган гомер – бәхет бит ул!

Миңа 34 ел дәвамында башлангыч сыйныф укучыларына аң- белем бирергә туры килде. Балаларны татар телендәбер – берсен аңларга, бер- берсе белән аралашырга өйрәтү, шуның белән бергә туган телгә, үзләре яшәгән җиргә, төбәккә мәхәббәт уяту, туган җирнең табигатен өйрәнү, анда яшәгән шәхесләрнең иҗаты белән кызыксыну, аларга карата ихтирам тәрбияләүне төп максатым итеп куйдым. Мин дәресләремдә балаларны санарга,алырга,кушарга өйрәтәм. Мин укучыларыма чын дус, сердәш, киңәшче булырга тырышам. Алар дәрестә куркып утырмасыннар, уйлансыннар, сораулар бирсеннәр, кызыксынсыннар, һәм аларның иҗади сәләтләре калкып чыксын өчен зур тырышлык салам.

Һәр бала үзе кечкенә дөнья икәнен бик яхшы аңлаган Сәйдел апа. Аларның холык-фигыльләре төрле булган кебек, уку материалын үзләштерү дәрәҗәсе дә төрле. Моны һәрвакыт игътибар үзәгендә тоткан ул. Шуңа күрә укытуның төрле алымнарын кулланган: кызыклы биремнәр, иҗади өй эшләре бирә иде.

Укытучы һөнәре бер урында таптануга, билгеле бер калып буенча эшләүгә корылмаган. Ул һәрвакыт эзләнүдә, яңа ачышлар ясарга омтылуда. Укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгаклапшуныәйтәсем килә: әгәр дә укытучы дәреснеукучыкызыксынырлыкитеп оештырса, ул, һичшиксез,эшендә уңышка ирешәчәк. Укытучы – баланың остазы да, киңәш бирүчесе дә, өлкән дусты да... Тормыштагы авыр вакыйгалардан яклаучысы да, җил – яңгырдан саклаучысы да.

Укытучы... Сәйдел апа.Ул укытып кына калмады, фикерләргә дә өйрәтте, уйларга юнәлеш тә бирде... Үрнәк алырлык һәм гыйбрәт булырлык хәлләр турында сөйләде. Минемчә, бу вазыйфаларны балаларны яраткан һәрбер укытучы башкара.

Көндәлекне ачып, үткәннәрне барлап утырам. Еллар үткән саен үткән гомернең, аралашкан кешеләрнең кадере арта бара. Тормышта хыялга илтә торган юлда җитәкләп баручыларга күңелдә туган рәхмәт, хөрмәт хисләре тагын да арта.

# РАЗДЕЛ II

## Тексты выступлений и мастер-классов педагогов - участников II Республиканского конкурса ораторского мастерства «SpeakingContest»

**Иностанные языки**

**МурзалиеваТамараАхнаповна**
**МБОУ «СОШ №33 с углубленным изучением английского языка»**

г.Нижнекамск

## Методы и приемы формирования коммуникативной компетенции на уроках английского языка

Основной целью обучения иностранному языку является формирование коммуникативной компетенции. Коммуникативное обучение иностранным языкам представляет собой преподавание, организованное на основе заданий коммуникативного характера. Это значит, что обучение должно быть организовано так, чтобы по своим основным качествам оно должно быть подобно процессу общения. Участие в общении предполагает овладение устной речью на иностранном языке т.е. формирование навыка говорения. При следовании принципу коммуникативной направленности вся система работы учителя подчинена созданию у ученика мотивации в говорении. Словом, в основе обучения устной речи должно быть общение, необходимость в общении, возможность общения, практика общения.

На уроках иностранного языка обучению обобщению способствуют методические приемы, которые имеют педагогический эффект в условиях:

- если учитель умеет чётко формулировать задания; умело использовать средства обучения;

- если учитель умеет создать благоприятные условия для речевой деятельности: когда учащимся хочется слушать иноязычную речь и им интересно, когда им хочется говорить и они не боятся сделать ошибку, когда учащиеся имеют возможность высказывать свои мысли, когда учащихся воодушевляют на высказывание, вселяют в них уверенность в том, что они могут справиться с заданием;

- если учитель верит в свои возможности научить учащихся пониманию иноязычной речи и умению вести несложную беседу и вселяет эту веру в своих учащихся.

II Республиканский конкурс ораторского мастерства посвящён Году театра в России. Тема и формат выступления – «Добро и зло» (монолог героя драматического произведения). Родовая специфика, «пограничное» положение драмы (между литературой и театром) обязывает вести ее анализ по ходу развития драматического действия (в этом принципиальное отличие разбора драматического произведения от эпического или лирического). Учитывая основные родовые категории драмы, мы воспользовались традиционной схемой, чтобы приблизиться к профессиональному овладению мастерством искусства ораторского чтения, начав с определения таких компонентов, как:

**тип конфликта;**

**система действующих лиц**, их место и роль в развитии драматического действия и разрешения конфликта;

**система мотивов** (в развитии сюжета и мотивов действия героя монолога);

**способ выражения авторской позиции** (ремарки, сценичность, поэтика имени, лирическая атмосфера).

Однако самым увлекательным был процесс выбора драматического произведения, монолога героя, составление партитуры и предварительное **чтение вслух**. Не зря конкурс носит название ораторского искусства. Требуется большая предварительная работа, чтобы «зацепить внимание» аудитории.

Мы полагаем, чтобы сохранить Язык и Литературу для детей «цифровой эры», важно также сохранить традиции и преемственность. Традиционными должны стать и конкурсы ораторского мастерства, и внеурочные занятия по риторике. Ораторскому мастерству всегда и везде придавали особое значение, потому что устная речь отражает интеллектуальное развитие, социальные навыки говорящего, способствует тому, чтобы сделать чтение модным, формирует эстетический вкус, интерес к Языку и Литературе.

**Шавалеева Рушания Мусавировна,**
**учитель русского языка и литературы**
**МБОУ «СОШ № 33» г. Нижнекамск**

## Работа с понятийным аппаратом, терминами как метод развития устной речи

Уважаемые коллеги, думаю, вы согласитесь, что знание литературоведческой терминологии обогащает устную (и письменную речь), воспитывает эстетический вкус, оберегает от поверхностного чтения, приближает читателя к сложному миру великих русских писателей, помогает раскрытию основной проблемы художественного произведения.

В данной методической разработке представляю свой опыт работы по формированию понятий на уроке литературы. Предлагаю вам вместе пройти путь от знакомства с термином (слово, словосочетание, обозначающее понятие), определения понятия (логическая операция, которая раскрывает его содержание)к формированию понятия (результат восхождения от анализа и синтеза свойств разнообразных объектов к выделению и закреплению их общих свойств через абстрагирование и обобщение). Поделюсь с вами, как я справляюсь с задачей перевода знания обучающегося с уровня представлений на уровень теоретического осмысления.

Процесс формирования понятия эффективен только при активной познавательной активности школьника, которая проявляется прежде всего в его устной речи. Предлагаю вам, коллеги, примерить на себя роль учеников 8 класса, которым предстоит осмыслить, что поэма М.Ю.Лермонтова «Мцыри» (первая группа) и рассказ М.Горького «Челкаш» (вторая группа) - произведения романтизма, и устно представить конечный продукт вашей совместной работы.

Формирование понятия осуществляется по схеме: ощущение (восприятие) - представление - понятие. У вас определение термина «романтизм» и тексты произведений. Предлагаю следующий алгоритм терминологической работы:

- начертить таблицу из двух вертикальных частей; внимательно прочитать определение;
- разделить определение понятия на смысловые фрагменты, пронумеровать;
- не нарушая последовательности, друг под другом, оставляя достаточно места, выписать смысловые фрагменты определения в левую половину таблицы;
- найти из художественного произведения цитаты, соответствующие содержанию смыслового фрагмента и иллюстрирующие его;
- вписать цитаты против смысловых фрагментов определения в правую половину таблицы;
- осознать выполненную работу как лабораторное исследование произведения на предмет осмысления понятия термина.

1.**Бытовое поведение героя, строй жизни подчиняется определённой философии**: «Я мало жил, и жил в плену. Таких две жизни за одну, но только полную тревог, я променял бы, если б мог». «Ты хочешь знать, что делал я на воле? Жил».

2. **Разлад мечты и реальности**: «В душе я клятву произнес: хотя б на миг когда-нибудь мою пылающую грудь прижать с тоской к груди другой, хоть незнакомой, но родной. Увы! Теперь мечтанья те погибли в полной красоте».

3.**Стремление героя к духовной свободе вопреки порядку вещей в мире**: «И в час ночной, ужасный час, когда гроза пугала вас, когда, столпясь при алтаре, вы ниц лежали на земле, я убежал. О, я как брат. Обняться с бурей был бы рад!»

4. **Исключительно герой в исключительных обстоятельствах**: «Я ждал. И вот в степи ночной врага почуял он, и вой протяжный, жалобный, как стон, раздался вдруг; и начал он сердито лапой рыть песок, встал на дыбы, потом прилег… Надежный сук мой, как топор, широкий лоб его рассек… Но вновь, хотя лила из раны кровь густой, широкою волной, бой закипел, смертельный бой».

5**. Яркий буйный пейзаж соответствует бурным страстям героя**: «Глазами тучи я ловил». «Ни одна звезда не озаряла трудный путь». «Гроза утихла. Бледный свет тянулся длинной полосой меж темным небом и землей, и различал я, как узор, на ней зубцы далеких гор».

6.**Психологизм, переживания, душевное движение героя**: «Меня могила не страшит: там, говорят, страданье спит в холодной вечной тишине; но с жизнью жаль расстаться».

Для учителя важно работать в русле формирования мотивации к овладению специальной терминологией. Учащимся предлагается понять логику построения определения термина, а в дальнейшем самостоятельно конструировать термин. Провести анализ понятия. Вычленить существенное и вторичное. Необходимо выяснить смысловое значение термина, выделить основные признаки. Когда учащиеся хорошо усваивают литературоведческую терминологию, у них повышается понимание проблемы, поднимаемой автором художественного произведения, активируется читательский интерес.

В данной разработке представлена наиболее продуктивная, на мой взгляд, система работы с определениями на уроке литературы посредством подбора цитат из произведения, поскольку умение правильного подбора - общеучебное познавательное УУД.

Цель современного образования соотносится с формированием ключевых компетенций (в частности, коммуникативной и языковой). Систематическая словарная работа преследует

своей целью формирование умения активно пользоваться литературоведческими терминами и понятиями, употреблять их в своей речи, устной( и письменной). По мере того, как речь школьника приобретает всё большую содержательность, расширяется возможность пользоваться речью как средством интеллектуальной деятельности. Обучающиеся не испытывают дискомфорта в дискуссиях, в выступлениях на семинарах , на научных конференциях.

На мой взгляд, такие результаты возможны при внедрении компетентностного подхода в обучении литературе, который предусматривает формирование коммуникативной компетенции. Предложенный опыт технологичен, он может применяться для развития устной (и письменной) речи обучающихся на разных этапах литературного образования.

# Татарский язык

**Гиниятуллина Алсу Рафисовна,**
**учитель родного языка и литературы,**
**МБОУ "СОШ №3" г.Нижнекамска**

**Тылсымлы ком һәм хыяллар**

План конспекты:

Исәнмесез! Хәерле көн барыгызга да!

Бүген мастер классымның темасы: <u>“Тылсымлы ком һәм хыяллар”.</u>

Хыялсыз кеше канатсыз кош, диләр. Әйе, менә мин дә нәкъ шул хыялый кешеләрнең берсе. Хыллану бит ул тормышта нинди дә булса максат куеп, шуны тормышка ашыру өчен, алга омтылып яшәү.

Беренче хыялым машина <u>йөртү</u> иде. (слайдта машина йөртеп төшкән фото) Бүген мин тормышымны машинадан башка күз алдыма китермим...

Ә икенчесе... балаларны үз артымнан <u>ияртү</u>... (слайдта балалар белән төшкән фото) ягъни, аларны төрле алымнар белән кызыксындырып, татар теле һәм әдәбияты дөньясына алып керү, аларга төпле белем бирү. Мин беренче хыялымны тормышка ашыру авыр булыр дип уйлаган идем, ә чынлыкта, икенче хыялымны тормышка ашыру авыррак булып чыкты, чөнки мин аны бүген дә һәр дәресемдә, һәрдаим тормышка ашырам.

Минем методик темам: “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә иҗади эш алымнарын кулланып, укучыларның телдән һәм язма сөйләм күнекмәләрен үстерү”.

Әлеге тема өстендә эшләгәндә мин нинди каршылыклар белән очрашам соң? Бүгенге авыр заманда, татар теленең, кызганычка каршы, тиешле дәрәҗәдә кулланылмавы заманында, балаларны татар теле һәм әдәбияты серләренә өйрәтү, бигрәк тә аларның сөйләм телен үстерү җиңелләрдән түгел. Шәһәр мөһитендә яшәүче укучылар татар телендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә генә аралаша диярлек. Телгә балаларның кызыксынуын ничек булдырырга? Бу сорау иҗади эшләүче укытучыларны бик тә кызыксындыра. (*Слайд)*

Федераль белем бирү стандартларына күчү шартларында укучының дәреслектәге кагыйдәләрне ятлап, дөрес итеп сөйләп бирү кебек формаль эшләр кәнәгатьләндерә алмый. Алган белемне киләчәктә кулланырга өйрәтү, укучының үзаңлылыгын һәм иҗади фикерләвен активлаштыру, иҗади эш алымнарына өйрәтү, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләре үстерү, сөйләм культурасын тәрбияләү - тел укытуга куелган төп таләпләр.

Иҗади эш алымнары, белгәнегезчә, бик күп төрле һәм мин аларны дәресләремдә, сыйныфтан тыш чараларда кулланам. Без әкиятләр уйлап, аларны сәхнәләштерәбез, һава торышы турында яки башка хәбәрләрне диктор ролендә сөйлибез, видеоязмалар, җырлар тыңлап аларга кушылып җырлыйбыз, хикәяләр, шигырьләр язабыз, аларны иҗади эшләр тактасына урнаштырабыз һәм газета журналларга бастырабыз, ял минутларында татар халык уеннары уйныйбыз.

Хәзер иң кызыклы, үзенчәлекле иҗади эш алымына тукталып китәсем килә.

“*Тәфтиләү” көе яңгырый.*

Әбием бүләк җибәргән,
Бүләкнең дә бүләге:
Энҗе калфак,чиккән камзул,
Татар кызы киеме!

Авылга кунакка кайттым,
Татар киемен киеп,
Әбием куансын әле
“Милләтем яши! “–диеп.

Кешелек дөньясы һәрвакыт матурлыкка омтылган. Гүзәллек белән янәшә үзең дә шәфкатьлерәк, мәрхәмәтлерәк булырга тырышасың. Халкыбызның күңел нурын сибеп чиккән киемнәре, бизәкләп тукыган ашъяулыклары, сөлгеләре, аның күңел байлыгын, матурлыкны тою сәләтен чагылдыра. Шуңа күрә без бу әйберләрне нәрсә дип атыйбыз?

-Әйе, күңел җәүһәрләре, күңел көзгесе, дип атыйбыз.

-Хәзер бүгенге темамыбызны тагын да ачыклау өчен, табышмак тыңлыйк!

- *Яңа гына идем итек. Ч өстәгәч, булам…*(читек)
- Димәк без сезнең белән нәрсә турында сөйләшәбез!
    - Әйе, читек турында сөйләшәбез. *(Слайд)Читек рәсеме.*
- Алдыбызга нинди максат куябыз? -Иҗади эшне башкарып аны яклыйбыз.
- Әйе, без бүген татар халкының милли киемнәре, күңел бизәкләре турында сөйләшәбез! Татар милли киемнәре үзе бер гүзәл дөнья.

- Кызганычка каршы, хәзер читекләрне музейларда, концертларда, телевизион тапшыруларда гына күрергә була. Безнең Татарстанда читекләр эшләп чыгаручы район бар, ул - Арча районы.
- **Мең тапкыр ишеткәнче, бер мәртәбә күрүең хәерле, - диләр.**

Хәзер иҗади эшебезне башлыйбыз. Сез эшне башкарганда бары тик татарча аралашып, кирәкле төсләрне бер-берегездән сорап алып, төшерелгән бизәкләрнең нәрсәләргә охшавына игътибар итеп эшләгез!

- *Аудитория белән уен.* Төркемнәр әлеге эшне башкарганда, әйдәгез без уйнап алыйк. Сезнең алда милли киемнәр белән пазллар. Әйдәгез бу рәсемнәрне төзеп нинди милли кием килеп чыкканын әйтегез. Аны проектта бирелгән диалогка охшатып бер-берегез белән сөйләшегез.

-*Бу нәрсә?* -*Бу камзул- татар милли киеме.*

-*Аны кемнәр кия?* -*Аны хатын-кызлар һәм ир-атлар кия. Ул өс киеме.*

-Парлашып эшлибез. *“Ак калфагым” көенә пазл җыялар*

- Әйдәгез хәзер төркемнәрне тыңлап алыйк.Читекне күрсәтеп төркемнән һәрберсе сөйли.

- *Без бүген төсле ком белән читек ясадык. Читек ул татар халкының милли киеме. Элек безнең әби – бабайлар бик яратып кигәннәр, ә хәзер аны бәйрәмнәрдә генә, сәхнәләрдә генә кияләр.*

*Читек искиткеч матур! Аны татар бизәкләре белән бизәдек. Бизәкләрдә үсемлек мотивлары чагылышы күбрәк.*

-Әйдәгез хәзер татар халкының җырлы-сүзле “ Башмакчы” уенын уйнап алабыз.

***Бала:*** Итек, читек, энә, без
Матур итеп тегәбез,
Читек башы чигәбез.
Кирәкмиме, алмыйсызмы?
Әллә киеп карыйсызмы?

***Түгәрәктәге балалар аңа каршы:***
И башмакчы, башмакчы,
Үзең оста такмакчы,
Син сайрама, такмагың,
Бир кияргә башмагың, - ***диләр***

*Аудитория белән эш.* Башмакны түгәрәк буенча бер-берсенә бирәләр. Музыка туктагач, читек кемдә кала шул әйтем, мәкаль яки табышмак әйтә.

Шулай итеп, без бүген мастер-классыбыз башында куйган максатларыбызга ирештекме? Эшебезгә нинди билге куя алабыз? *Аудиториягә таратылган төрле төстәге орнаментларны күтәрәләр.*

Хәзер сезнең игътибарыгызга эш тәҗрибәмнән видеоязма тәкъдим итәм. (*Видеоязма)*

Мин сезгә берничә иҗади эш алымын күрсәттем. Рус төркемендәге укучылар да бик рәхәтләнеп татар телендә сөйләшәләр. Беренче иҗади эш алымымның максаты: "Төсле ком белән рәсем ясау аша балаларның сөйләм телен үстерү". Бу иҗади эш алымы аеруча үзенчәлекле һәм нәтиҗәле. Эш барышында балалар үзара бары тик татарча аралашып кына төркемнәрдә эшлиләр һәр ясалган иҗади эшне проект итеп якларга өйрәнәләр. Бу эшләрне без дәрес буена түгел, ә дәреснең бер өлешендә генә башкарабыз. Бу укучылар өчен ял минуты да булып тора. Әлеге иҗади эш алымнары хезмәт, рәсем, әйләнә-тирә дөнья, җыр дәресләре белән дә предметара бәйләнешне күрсәтә. Бүгенге көндә мин төсле ком белән рәсем ясау аша балаларның сөйләм телен үстерү турында авторлык программасы өстендә эшлим.Үземнең чыгышымны балаларның дәрестә иҗат иткән **синквейн** белән тәмамлыйсым килә.

Ком.

Тылсымлы һәм серле.

Уйната, уйлата, сөйләм телен үстерә.

Татар телен өйрәнергә безне бик дәртләндерә.

Ул - иҗади эш төре.

Менә шулай итеп, мин үземнең икенче хыялымны тылсымлы ком кулланып та, тормышка ашырам. Сезнең дә теләкләрегез тормышка ашсын! Хыялларга омтылып яшик!

**Камбеева Гюзель Галимзяновна,**
**учитель родного языка и литературы**
**МБОУ СОШ №33 НМР РТ**

## Развитие навыков устной речи у учащихся на уроках родного русского языка

«То, что изучается с удовольствием, изучается скорои основательно усваивается».
*Иоганн Гербарт, немецкий философ, педагог*

Обучение русскоязычных детей татарскому языку я сопоставляю с изучением иностранных языков. При обучении возникает множество проблем. К ним относятся проблема повышения эффективности обучения устной речи, которая непосредственно связана с разрывом между теорией и практикой и пассивным характером учебной деятельности, тогда как абсолютной ценностью общества становится образованная активная личность, способная к непрерывному самообразованию, саморазвитию и самосовершенствованию.

Существует следующая гипотеза:если в процессе обучения устной речи использовать современные педагогические технологии (например, использование проектной деятельности обучения), то это позволит повысить эффективность обучения данному виду речевой деятельности.

В языковой области целью обучения языку при коммуникативной методике предполагается обучение общению на татарском языке в устной и письменной форме в рамках речевой ситуации.

Как известно, способом устно-речевого общения является говорение. Цель обучения говорению в школе и есть развитие у учащихся способности в соответствии с их реальными

потребностями и интересами осуществлять устное речевое общение в разнообразных ситуациях.

Чтобы способствовать общению учащихся мы должны учитывать специфические признаки данного вида речевой деятельности, такие как мотивированность, целенаправленность, активность, связь с личностью и мыслительной деятельностью человека, эвристичность, самостоятельность, темп и ситуативность. Если есть цели и мотивы общения, учтены характерные особенности участников общения, их возраст, уровень развития и т.д., то акт общения в рамках какой-либо речевой ситуации, безусловно, состоится.

Для создания данных условий в процессе обучения татарскому языку я использую приемы активизации и свою методическую тему «Развитие интеллектуальных способностей младших школьников посредством использования игровых технологий», которые учитывают все выше перечисленные признаки устного речевого вида деятельности. Преимущества этих приемов в том, что учащиеся, активно участвуя в процессе обучения, начинают обдумывать, вспоминать, использовать изученный языковой материал.

Здесь я думаю, уместно вспомнить слова Василия Александровича Сухомлинского: «Игра-это огромное светлое окно, через которое в духовный мир ребенка вливается живительный поток представлений, понятий об окружающем мире». Обучая посредством игры, я учу детей:

1. КЛАССИФИЦИРОВАТЬ. Игра называется «Собери рисунок». Рисунок разрезается на несколько частей, и на каждой части пишется задание. Это задание развивает мелкую моторику рук, воображение, творческое и художественное мышление, воспитывает усидчивость, аккуратность.
2. ОБОБЩАТЬ.Игра называется «Кто ты такой?». Эта игра на развитие умения находить признаки, обобщать их, учатся выражать свое мнение, учатся выступать перед сверстниками.
3. ЖЕЛАТЬ ДОКАЗЫВАТЬ. Игра называется«Хорошо-плохо» - игра дает возможность выражать свое мнение и отстаивать их среди других множеств.
4. ВЫДЕЛЯТЬ ГЛАВНОЕ. Одой из основных задач в начальной школе является задача – научить ребенка читать. Читать не просто на родном для него языке, а научить его читать для него на незнакомом татарском языке. Одна из интересных называется «Оживи букву». (Чтобы дети лучше запоминали буквы, предлагается им их оживить, т.е. самим превратиться в БУКВУ.

«Вот я, вот я – превращаюсь в букву Я.

А теперь, а теперь – превращаюсь я в букву Р» и др. В ходе этой игры дети еще и учатся общению, т.к. некоторые буквы можно показать только в паре.

5. ФАНТАЗИРОВАТЬ. «Новое назначение предмету» - эта игра развивает воображение и мыслительную деятельность. Предлагается какому-либо предмету придумать новое назначение.Например: зонт – для переноса мягких игрушек, канцелярские зажимы – подставка для мобильного телефона и др.

Каждая игра – учит, активизирует познавательную деятельность; игровой материал запоминается быстрее и дольше. Следовательно, это эффективное средство обучения.

ИГРАЮТ ЛЮДИ НА ПЛАНЕТЕ,
ИГРАЮТ ПТИЦЫ И ЖУКИ,
ИГРАЮТ ВСЕ, НО ТОЛЬКО ДЕТИ
ИГРАЮТ ОТО ВСЕЙ ДУШИ!
И ЕСЛИ В ШКОЛЕ НА УРОКЕ ПОВЕДЕТСЯ ПОИГРАТЬ,
ТО, НЕТ СЧАСТЛИВЕЙ ИХ НА СВЕТЕ,
И ВЫУЧАТ ВСЕ ВСЁна «5»!

Закончить я хочу словами Конфуция: «Учитель и ученик растут вместе». Так пусть игровые технологии позволяют расти, как ученикам, так и учителю!

**Нургатина Раилә Раиф кызы**
**”Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33 нче гомүми урта белем бирү мәктәбе”нең туган тел һәм әдәбият укытучысы**

## Татар теле дәресләрендә, уен формалары кулланып, укучыларның сөйләм телен үстерү

Рус телле балалар белән эшләгәндә, игътибарны сөйләм телен үстерүгә юнәлтергә кирәк. Укучыларга сүзләрне, җөмләне мәҗбүри ятлатып, әллә ни уңышка ирешеп булмаячак. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, сөйләм телен үстерү максатыннан, төрле формадагы уеннар куллану отышлы алым дип саныйм. Ул кайбер балалар өчен хыялллану, кайберләренә күңелле ял итү чарасы да булып тора. Уен һәрвакыт эмоция һәм акыл таләп итә, шулай ук тиз арада җавап кабул итүне сорый (ничек җавап бирергә, нәрсә эшләргә, ничек җиңәргә?). Бу сорауларны чишәргә тырышу уйнаучыларның уйлау эшчәнлеген көчәйтә. Уен барышында балаларның татарча сөйләшергә тырышулары бик зур уңай факт булып тора. Уен алымнарын, эш төрләрен төрлечә сайларга мөмкин. Ләкин һәр уен ныклап уйланылган, һәрьяклап эшкәртелгән булырга тиеш.

Уенны оештырганда, түбәндәге максатларны күз алдында тоту мөһим:

1) укучыларның аралашу (коммуникатив) эшчәнлеген активлаштыру;
2) сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, рольләрне дөрес бүлү;
3) тормышта укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрдән файдалану;
4) үзара ярдәмләшү, телдән дөрес актив аралашу мохиты булдыру.

Бигрәк тә чит телгә өйрәтүдә уен эшчәнлегенә нигезләнүгә нык басым ясала. Бу турыда Ефим Израилович Пассов “Мәктәптә чит тел дәресе”, Алексей Николаевич Леонтьев “Урта белем бирү мәктәбендә чит телгә өйрәтү методикасын камилләштерү” исемле хезмәтләрендә ассызыклыйлар. Шуларга нигезләнеп, мин дә һәр дәресемне уен эшчәнлегенә таянып оештырырга тырышам. “Хәзер уйнап алырбыз” сүзен балалар дәрес саен көтеп алалар. Уеннар бик күп төрле.

Гадәттә аларны берничә төркемгә бүлеп йөртәләр:

- әле өйрәнелмәгән лексиканы үзләштерергә ярдәм итүче уеннар. Мин үз эшчәнлегемдә бу этапта “Уйлап тап!” уенын кулланам. Бала такта янына чыгып, бер сүзне сүзлегеннән укытучыга күрсәтә, калганнар аның ни уйлаганын белергә тиеш.
- өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итүче уеннар. Бу этапта исә "Нәрсә качкан?" "Чайнворд", “Кар атышлы”, “Кар йомарламы” кебек уеннар кулланам. “Белмәмеш”- дәрес башында сөйләм телен үстерүгә этәрүче кулай уен. Такта алдына Белмәмеш чыга да, укучыларга һава торышы, атна көне турында сораулар яудыра, калганнар җавап бирә, шул рәвешле укучылар арасында диалогик сөйләм формалаша. Төрле текстларны укыгач, рольләрне балалар уйнап ала, чын актерлар рәвешенә кереп, киемнәр алып килеп, уенчык савыт-сабалар кулланып, үзләренең сөйләм теленә җиңел генә чыкканнарын сизми дә калалар. Шунда ук жюрилар актерларга бәя дә бирергә мөмкин. Алар (Р. Хәйдарова технологияләре буенча) “сәнгатьле сөйли”, “рольне оста уйный”, “сүзләрне белә” дип, уйнаучыларны канатландырып та җибәрә.
- грамматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар. Мин үзем, бик рәхәтләнеп, “Имтихан” уенын кулланам. Карточкага сүзтезмәләр язам да, укучылар чыгып билет ала, анда язылганнарны тәрҗемә итә.
- грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче уеннар. Мәсәлән, “Капка”, “Фоторобот төзү”, төрле типтагы рольле уеннар: “Кибеттә”, “Кунакта” һ.б. Кибеттән ташламалар өчен ясалган брошюраларны алып киләм: күрсәтмәлелек әзер. Укучылар кайсы нинди бүлектә, кем сатучы, кем сатып алучы булачакларын бүлешеп, рәхәтләнеп, дәрес вакытында “Пятерочка” кибетенә барып, татарча аралашып кайталар. Сөйләм теле ныгый, саннар кабатлана.

Туган тел һәм әдәби уку дәресләрендә уеннар материалның үзенчәлеге һәм эчтәлегенә, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә карап, дәреснең өч этабында да: белемнәрне актуальләштергәндә, яңа тема өйрәнгәндә һәм ныгытканда да кулланыла.

Димәк, дәресләрне уен эшчәнлегенә нигезләнеп оештыру билгеле бер нәтиҗәне күрергә ярдәм итә: укучылар белем алып кына калмыйлар, ә аларны аңлыйлар, кулланырга өйрәнәләр, анализ ясый һәм бәяли алалар. Укучыларның кызыксынуларын арттыру нәтиҗәсендә, уен алымнары, һичшиксез, сөйләм телен үсерүгә ярдәм итәчәк.

**Нуруллина Айгөл Әхсән кызы**
**"Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33 нче гомүми урта белем бирү мәктәбе"нең туган тел һәм әдәбият укытучысы**

## Күп мәгънәле һәм синоним сүзләр кулланып балаларның сөйләм телен үстерү

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй фикерләрен тиешле эзлеклеклелектә, ашыйкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, сөйләм үстерү юнәлешендә даими эш алып барырга кирәк. Баланың сөйләм телен үстерү, халык әйткәнчә, балага «тел ачкычы» бирү, аның фикер йөртү сәләтен үстерү белән бер диярлек, чөнки тел үсү аң үсү белән табигый бәйле.

Фикерләү сәләтен үстерүдән башка гына сөйләм телен үстерү белән мавыгу — ул балаларны эчтәлек турында җитди уйламыйча сөйләргә өйрәтү булыр иде.Шуңа күрә, балаларның сөйләмен телен үстерү һәрвакыт аларның фикерләвенә нигезләп алып барыла. Баланың сөйләм теле турында кайгырту аның фикер йөртүен уяту белән бергә эшләнә. Бу инде укучы, нык күңел биреп, төшенергә, аңларга омтылсын, истә калдырырга тырышсын; аның күзәтүләре анализлар белән, охшаш һәм аермалы якларны табу белән, төркемләү, гомумиләштерү һәм системалаштырулар белән, аңлатулар, исбатлаулар һәм дәлилләүләр белән бәйләнгән булсын дигән сүз. Нәкъ шундый шартларда гына укучының тулы кыйммәткә ия булган сөйләмтеле формалаша ала.

Мин уку дәресләрендә сүзлек өстендә эшләү укучыларның фикерләүләрен һәм сөйләмнәрен үстерүнең әһәмиятле шарты булып торадип уйлыйм. Яңа сүзне аңлату һәм аны аңлаганлыкларын тикшерү белән генә чикләнми,әукучының сөйләменә кереп китәргә тиешле сүзне аерып алып, дәреснең барлык этапларында, хәтта дәрестән соңгы эшләрдә дә сөйләмнәрендә куллануларын булдырырлык шартлар тудыра.

Дәрескә әзерләнгәндә үк, укытучы түбәндәге эшләрне башкара:

1.Текстта синоним сүзләр бармы, булса, мәгънә төсмерләрен ничек күрсәтергә, нинди сорау куйганда, балалар бу җөмлә өчен кирәкле кайсы сүзне куллана алырлар.

Мәсәлән, Г. Тукайның «Буран» шигыреннән "ява" мәгънәсендәге фигыльләр билгеләтелә *(оча, котырына, бәрә*). Тукай кар явуга карата шундый сүзләрне ни өчен кулланган? Алар карның нишләгәнен белдерәләр?

2.Әгәр текстта сүзнең синонимы булмаса, аны дәрестә сөйләмгә кертеп җибәрергә кирәк булган вакытта, түбәндәге юллар белән эшләргә була: укытучы укубарышында аңлашылмый торган сүзләрне аларның синонимнарын әйтеп аңлата, йә булмаса әңгәмә вакытында, яисә рәсем өстендә эшләгәндә, текст эчтәлеген сөйләгәндә, сөйләм эченә кертеп җибәрә.

Мәсәлән, Идрис Туктарның «Өлгер» хикәясен укыганда, әңгәмәсе вакытында «*өлгер, уңган, җитез, елдам*» сүзләре нәрсәләре белән бер-берсенә охшыйлар?» дигән сорау куеп, синоним сүзләрнең мәгънә төсмерләрен билгеләтә: нинди бала өлгер, уңган була? (булдыклы, эшне вакытында эшләп бетерүче бала өлгер, уңган була).

3. Балаларның кайбер синоним сүзләр белән таныш булуы ихтимал; мәсәлән, II сыйныфта *батырлык, геройлык* синоним сүзләрен беләләр, ә III сыйныфта бу синоним сүзләр оясына *фидакарьлек, каһарманлык, баһадирлык, кыюлык* синонимнары да өстәлә. Укучылар, эчтәлекне сөйләгәндә яки сорауларга җавап биргәндә, шул сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап кулланалар.

Синоним өстендә эшләү шуның өчен әһәмиятле, чөнки алар:

а) сөйләмне төрләндерә;

б) сөйләмдә төшенчәне, уйны төгәл белдерергә ярдәм итә.

Синонимнар арасыннан теге яки бу сүзне сайлаганда, иң әһәмиятлесе—алар арасындагы мәгънә уртаклыгын белү түгел, ә һәр сүзнең мәгънәви бизәгендәге аерманы тотып алу, нәрсәләре белән алар бер-береннән аерылганын — төсмерен сиземли белү.

Баланың сөйләм телен үстерүдә күп мәгънәле сүзләр өстендә эшләү күнекмәләре аеруча әһәмиятле.

Бер сүз белән берничә сүзтезмә бирелә: алтын **сәгать,** *алтын арыш, алтын куллар, алтын кеше.* Балалар туры яки күчерелмә мәгънәдә булган сыйфатларны табып язалар: *алтын арыш— сап-сары булып өлгергән арыш, алтын куллар — оста куллар, алтын кеше— яхшы кеше.* Күчерелмә мәгънәдә йөргән сүзләрнең мәгънә катламын төрле сүзтезмәләрдә күрсәтеп була: **итек баса,** *су баса, камыр баса, болыт баса.*Аларның мәгънәләре ачыграк аңлашылсын өчен, синонимнар табарга кирәк була: *киез итек ясый; су җәелә; камыр изә, ясый; болыт каплый һ. б.*

Укучылар сүзләрнең күчерелмә мәгънәдә, күп мәгънәдә кулланылганын практик өйрәнәләр, үзләре дә сөйләмнәрендә шуларны куллану күнекмәләре алалар. Бер очракта туры, икенче очракта күчерелмә мәгънәдә кулланылган мисалларны чагыштыралар: *төенне чишә — серне чишә, кыска чәч — кыска хәтер, көмеш акча — көмеш тавыш һ. б.* Аннары укучыларның үзләренә, туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланып, сүзтезмә ясап язарга мисаллар бирелә. Туры мәгънәдә кулланылган ике сүзтезмәдән күчерелгән мәгънәле өченче сүз-тезмә ясату (**көмеш** кашык, ак **чәч** — көмеш чәч; **алтын** йөзек, сары **яфрак** —алтын яфрак) күнегүләре дә сүзләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылу җирлеген аңларга ярдәм итә.

Сөйләм үстерүнең барлык бу формалары баланың аң үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Укучы, үзенең уен формалаштырганда, аның сөйләм формасы өстендә дә эшли, һәм, киресенчә, баланың сөйләмен үстерү белән, без аның уй культурасын, фикер йөртү сәләтен үстерү өстендә дә эшлибез.

Тел – кешеләрнең иң мөһим аралашу-аңлашу коралы. Телдән сөйләмгә өйрәнү,белем һәм тәрбия алу,дөньяны танып-белү, иҗат итү эшләре – барысы да тел ярдәмендә генә тормышка ашырыла.

**Шәйдуллина Фәндия Камил кызы**
**”Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33 нче гомүми урта белем бирү мәктәбе”нең**
**туган тел һәм әдәбият укытучысы**

## Укучыларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү

Укучының гомуми үсеше, барлык уку предметлары буенча өлгереше үз фикерен ни дәрәҗәдә эчтәлекле, логик эзлекле һәм дөрес итеп белдерә алу сәләтенә бәйле.

Рус педагогы К.Д.Ушинский укучыларда тел үстерү эшенең психологик нигезләрен ача, телне фикергә, фикерләүне телгә бәйләп карый. Ул үзенең хезмәтләрендә баланың сөйләм телен үстерү мәсьәләсенә зур урын бирә. Галим – педагог баланы үз телендә сөйләмгә өйрәтүнең хәлиткеч урын тотуын раслаган. Ул сөйләм үзләштерүен фикер йөртә белүе белән бәйләнештә караган. Укытуның башлангыч чорында ук укучыларга тел үстерү күнекмәләрен бирә башларга кирәклеген әйтә. К.Д.Ушинский туган телне белем чишмәсе дип атый: аның фикеренчә, тел - иң яхшы укытучы, акыл өйрәтүче генә түгел, бәлки, әйләнә-

тирәдәге табигать, җәмгыять тормышы белән таныштыручы да. Ана теле дәресләрендә баланың сөйләм телен үстерү эшен системалы рәвештә алып барырга чакыра.

Татар теле методистларыннан Г.Ибраһимов, М.Корбангалиев, М.Галләмова, М.Фазлуллин һ.б. үзләренең методик хезмәтләрендә укучыларга тел үстерү күнекмәләре бирү һәм аларның сүзлек байлыгын арттыру мәсьәләләренә тукталалар, бу өлкәдә төрле метод һәм алымнарны кулланырга тәкъдим итәләр.

Билгеле булганча, укучыларда татар сөйләме күнекмәләренә башлангыч сыйныфта нигез салына. Алдагы сыйныфларда ул камилләшә, тел буенча мәгълүматлылык арта, тирәнәя төшә, нәтиҗәдә ныклы бер системага әверелә. Алдыма куелган бурыч һәм максатларны гамәлгә ашыру өчен, мин заманча технологияләрне файдаланып, төрле иҗади эш алымнарын киң кулланып, дәресләремне мавыктыргыч, нәтиҗәле итеп оештырырга тырышам.Укуның беренче көннәреннән үк укучылардан сүзлек булдыруларын һәм өйрәнелә торган яңа сүзләрне системалы рәвештә язып баруларын таләп итәм. Шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзибез. Аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдаланабыз. Мондый эшләр укучыларның сүз байлыгын арттыра, бәйләнешле сөйләм оештырырга ярдәм итә.

Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру өчен, укучыларда уку теләге уяту мөһим. Шул максаттан кабинетта татарча газета-журналлар, китаплар туплыйм. Һәр дәрес биш минутлык пышылдап уку белән башлана. Бу эш укучыларга да бик ошый. Бердән, ул укучыларның сөйләм күнекмәләрен камилләштерсә, икенчедән, йөгерек укуны үстерә.

Дәрес башында төрле рәсемнәр буенча кыска күләмле хикәяләр төзү, һава торышы турында сөйләтү, предметларны билгеләре буенча тасвирлау кебек эшләр, бердән, укучыларны эзләнергә, уйланырга мәҗбүр итсә, икенчедән, сүз байлыгын, сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерә.”Авыр” сүзләрне иллюстрация материаллары кулланып аңлатам. Мәсәлән, 2 нче сыйныфта Газинур Моратның “Иң матур ил” шигырендә шәҗәрә сүзе очрый. Шигырьдә “Безнең шәҗәрә агачы” диелә. Шәҗәрә агачы сүзтезмәсенә белешмә бирелү белән беррәттән, дәреслектә рәсем дә бирелгән. Рәсемгә карап, балалар шәҗәрә агачының төп мәгънәсен ачыклыйлар, күзаллыйлар. Шәҗәрә сүзен ничек аңлауларын дәлилләп бирәләр.”Авыр” сүзләрне синонимнары аша аңлату да уңай нәтиҗә бирә. Мәсәлән, Әминә Бикчәнтәеваның “Тәмле сүз” әсәрендә очраган шелтәләде - ачуланды; тупас сүз - ямьсез сүз сүзләрен синонимнары аша аңлатам.

Дәрестә бирелгән теманы ачу өчен, план буенча сөйләшү алып барабыз. Сөйләшүләр барышында видеоязмалар куллану, музыка, җыр тыңлау дәрескә җанлылык кертеп җибәрә. Мәсәлән, туган авыл турында үткәндә дәрестә авыл табигате, урманнары, чишмәләре, болын-кырлары төшерелгән видеоязма күрсәтү – гади авыл гына түгел, ә искиткеч матур туган авыл турында җанлы сөйләшү тудыра. Бер үк вакытта туган авыл өчен горурлык хисләре дә уяна.

Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре өчен алдан план төзү дә бик уңышлы. Планның һәрбер пункты буенча әңгәмә алып барылганнан соң, нәтиҗә ясау мөһим. Нәтиҗәләр ясаганда, татар халкының мәкаль, әйтемнәреннән, халык җырларыннан файдаланам.Әкиятләр белән танышканнан сон, йомгаклау дәресе итеп,”Әкият геройлары” дигән әкият - дәрес үткәрәм. Сыйныф өч төркемгә бүленә. Һәр төркем үз герое турында китаплар туплыйлар.Өйрәнгән әкиятләрдән аерым эпизодларны сәхнәләштерәләр. Иҗади коллектив эшендә катнашалар.

Шулай ук дәресләрдә милли-төбәк компонентына караган материалларны да еш кулланырга тырышам. Дәресләрдә татар этнокультурасын, тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын киңрәк чагылдырган текстлар сайлап алам, текстка сораулар төзибез, сорауларга җаваплар бирәбез. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә милли-төбәк компонентын мин дәреснең төрле этапларында һәм төрлечә кулланам.Төбәгебездә яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм язучыларыбызның иҗаты белән һәрдаим кызыксынып торабыз, алар турында мәгълүмат тупланган папкалар булдырылды.Укучылар төбәгебез шагыйрьләренең шигырьләрен өйрәнәләр. Дәрестә балаларны да иҗатка тартырга тырышам.

Аерым алганда, табышмаклар, мәкальләр,санамышлар,шигырьләр ятлау, балаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора. Шуңа күрә дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда мондый эшләргә дә игътибарны юнәлтәм. Укуның беренче көннәреннән үк укучыларны татарча газета-журналлар белән таныштырам , татарча спектакльләргә , концертларга йөрергә, татар телендә телевидение һәм радио тапшыруларын карарга күнектерергә тырышам. Класстан тыш чаралар үткәрү дә балаларны дөрес, матур, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтә, аларны татар әдәбияты, татар халкының җыр-музыкасы белән таныштыруда, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүдә зур роль уйный. Берничә ел рәттән укучыларны төрле конференцияләргә әзерлим, күп эзләнү эшләре алып барабыз.

Экскурсиягә баргач күргәннәре буенча хикәяләр төзеп сөйлибез, фикер алышабыз Мәктәптә һәм мәктәптән тыш урыннарда чыгышлар ясау укучыларның иҗади сәләтләрен һәм мөстәкыйльлеген үстерә. Төрле темаларга докладлар ясау, рефератлар яздырту да балаларның сөйләм телен баета, кеше арасында чыгыш ясарга өйрәтә. Укучылар шагыйрьләр һәм язучыларның тормышы, иҗаты турында, төрле үсемлекләр, хайваннар турында рефератлар язарга яраталар һәм дәрестә аларны яклыйлар.

Укучыларның ана телен өйрәнүгә кызыксынуы, омтылышы, иҗади эзләнүләргә теләге, үз милләтенә, теленә мәхәббәте көннән-көн үсә, тел буенча мәгълүматлылыгы арта, тирәнәя төшә

Димәк, рус мәктәбендә укучы татар балаларын бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү дәвамлы һәм мөһим бурычлардан санала. Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре укучыларны дөрес, матур, үтемле һәм аңлаешлы итеп сөйләргә, укып аңларга һәм аңлата белергә, теге яки бу мәсьәләгә карата үз фикереңне белдерергә, иҗади эшләр белән шөгыльләнергә өйрәтәләр. Укытучы укучыларга бәйләнешле сөйләм күнекмәләре бирүгә тиешле урын биреп, дәрестәге һәм дәрестән тыш эшләрне укучыларның сөйләү күнекмәләрен үстерергә ярдәм итәрлек итеп оештырырга тиеш. Ул үз эшенә иҗади якын килеп, төрле эш төрләрен, методик алымнарны сайлый белсә, аларны урынлы һәм иҗади кулланса, шулай ук аларны үзгәртә , тулыландыра белсә, укытуда ул үзе көткән нәтиҗәләргә ирешә алыр.